Илдар Сәгъдәтшин:
«Татар китабы сезгә үзе киләчәк»

«Чит төбәкләрдә яшәүчеләрнең ихтыяҗын күз уңында тотып, без интернет-кибет булдырдык. Аңа шушы адрес буенча керергә була – www.tatkniga.ru. Заманча технологияләр буенча эшләнгән бу кибеттә яңа чыккан һәр китап белән танышырга, сатып алырга мөмкин. Анда компьютердан да, кесә телефоныннан да керергә була».

5 БИТ

Уяу бул!

Быелның өч аенда алдакчы-мошенниклар Казан халкының 12 миллион сумлап акчасын үзләштергән. Бу – талап түгел, ә кешеләр үз куллары белән чыгарып тоттырган, банк картасыннан яки телефоннан күчергән акчалар.

4 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 21.04.2017 | № 43 (5805)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

КАРЛЫ АПРЕЛЬ

Урамда кабат кыш. Апрель кары чәршәмбе көнне Лениногорск, Кама Тамагы, Азнакай, Әлмәт, Бөгелмә, Баулы районнарында яшәүчеләрне гаҗәпләндерсә, кичә Казанга да килеп җитте. Чакрымнарга сузылган бөкеләр, юл һәлакәтләре, ут чыбыклары өзелү, ауган агачлардан зыян күргән кешеләр, тагын бик күп көтелмәгән «күчтәнәч»ләре белән истә калачак карлы апрель азагы.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Эльвира МОЗАФФАР

УТ ЮК

Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан идарәсе хәбәр итүенчә, кичә һава торышының начарлануы сәбәпле, республикада 41 авылда ут чыбыкларына зыян килгән. Тәтеш, Яшел Үзән, Кама Тамагы, Кайбыч, Балык Бистәсе, Питрәч районнарында, Казанның кайбер урамнарында яшәүче барлыгы 10 меңнән артык кеше, шул исәптән кайбер балалар бакчалары, мәктәпләр утсыз калган. Авария бригадалары кичә ярты көн ут чыбыкларын ялгау, җитешсезлекләрне көйләү белән мәшгуль булдылар. Төштән соң районнарга ут бирелгән иде инде.

КӨЧЛЕ ҖИЛ

Арчаның Шурабаш авылында көчле җил берәүләрнең гараж түбәсен каерып аткан. Казанда җил агачларны да аударган. Нәтиҗәдә Гафури урамында машиналарга зыян килгән. Совет районында бер хатын-кыз җилдә ауган агач астында калган. Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, зыян күрүче җитди имгәнгән, сынган урыннары да күп. Аны шәһәрнең 7нче хастаханәсенә озатканнар.

ЮЛЛАР

Күпләр автомобильләрен җәйге тәгәрмәчләргә күчерергә өлгергәннәр иде. Шуңа да карлы яңгыр аркасында хасил булган бозлавык юлда йөрүчеләр өчен аеруча куркыныч тудыра. ЮХИДИ хезмәткәрләре юл хәрәкәте катгыйдәләрен катгый рәвештә сакларга һәм юлларда бик игътибарлы, сак булырга кирәклеген искәртә. Машина йөртүчеләргә тизлек режимын сакларга, куркыныч маневрлар ясамаска, бик кирәк булмаганда, юлга чыгудан тыелып торырга киңәш итә.

Кызганыч, көтелмәгән буран юл һәлакәтләренә дә китергән. Мәскәү – Уфа трассасы буйлап Питрәч районында, йөк машинасы белән җиңел автомобиль бәрелешүе нәтиҗәсендә, ике кеше һәлак булган. Тагын ике зыян күрүче Питрәч районы хастаханәсенә озатылган. Казаннан Яшел Үзәнгә бара торган юлда «КАМАЗ» юл читенә очып чыгу аркасында, хәрәкәт тоткарланган.

Җәмәгать транспорты – трамвай һәм троллейбус линияләре дә кичә бозланган иде. Иртәнге сәгатьләрдә Киров дамбасында 20ләп трамвай хәрәкәтсез калды. ГЛОНАСС системасы мәгълуматлары буенча, муниципальара маршрутларга юл, һава шартлары уңайсыз булганлыктан, 83 рейс автобусы билгеләнмәгән.

→ Ахыры 2нче биттә.

Ата-аналарны нәрсә борчый?

26 апрельдә Татарстанда беренче тапкыр «Хатын-кыз игътибары» «кайнар линия»се эшли башлый. Оештыручылар, киләчәктә ул кварталга бер тапкыр булачак, дип вәгъдә итә.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Шул уңайдан Татарстан Дәүләт Советында узган матбугат конференциясендә билгеле булганча, бу юлы «кайнар линия»нең темасы итеп мәктәпкә 1нче сыйныфка кабул итү, балалар һәм үсмерләрнең җәйге ялын оештыру мәсьәләләре алынган. Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары, «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе Татьяна Ларионова сүзләренчә, «кайнар линия»не алар Татарстанда кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская белән берлектә оештыра.

– Гадәттә, мәктәпкә кабул итү эшләре май аенда ук башлана. Узган еллардагы практикадан күренгәнчә, бу өлкәдә проблемалар да килеп чыга, бигрәк тә Казан, Чаллы, Әлмәттә. Мәктәпкә баручы балаларның саны да артып тора. Узган елны 1нче сыйныфка 45 321 бала килсә, быелгы уку елында 46 471 бала кабул ителәчәк. Баланы мәктәпкә алмау очраклары да булгалый, шуңа да бу проблеманы аерым карап тикшерү мөһим, – диде ул журналистларга.

«Кайнар линия»нең икенче темасы – балаларның җәйге ялын оештыру һәм эшкә урнаштыру мәсьәләсе дә бик актуаль. Җәйге каникул чорында ата-аналар балаларын лагерьга урнаштыруны да кайгырта. Татьяна Ларионова, соңгы өч елда 36 лагерьда капиталь төзекләндерү булды, диде. Быел да әлеге эшләр дәвам иттерелә, моның өчен 100 миллион сум акча бүлеп бирелгән. Җәйге лагерьларда бу юлы 218 мең бала ял итәчәк (узган елны бу сан 215 мең булган).

– Узган ел «Мәрхәмәт» берләшмәсенең күчмә утырышлары вакытында сәламәтлеге начар, инвалид балаларны лагерьларда ял иттерү мөмкинлеген карарга кирәк дигән нәтиҗәгә килгән идек. Быел начар ишетүче балаларны Бөгелмә, Чаллы, Тәтеш, Мөслим районнарындагы лагерьлар кабул итәчәк, – диде берләшмә җитәкчесе.

Татарстанда кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская да ата-аналарны борчыган мәсьәләләргә тукталып үтте.

– Республикага килүче мигрантларның саны артып тора. Шуның белән бәйле рәвештә мәктәпләрдә аларның балаларын укыту буенча сораулар да еш туа. Узган елны 10нчы сыйныфка кабул итү буенча берничә шикаять булды. 1нче сыйныфка барганда нинди документлар тапшырасы, медицина белешмәсе кирәкме, тест бирдереп кабул итү никадәр законлы, җәйге ялларны ничек куркынычсыз уздырып була – ата-аналарны борчыган сораулар бик күп. Шуңа да «кайнар линия» оештыру аларга җавап табарга булышыр дип ышанасы килә, – диде ул.

«Кайнар линия» телефоннары: (843) 236-00-71, 236-40-17 *һәм* ***236-40-62.***

Сораулар иртәнге 8дән 19.00 сәгатькә кадәр кабул ителә. Татарстанда яшәүчеләрнең сорауларына Дәүләт Советы депутатлары, Татарстанның Мәгариф һәм фән, Яшьләр эшләре һәм спорт, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыклары вәкилләре, кеше хокуклары, бала хокуклары буенча аппарат хезмәткәрләре, «Җәй» үзәге, Татарстан яшь юристлар ассоциациясе, Казан, Чаллы һәм Әлмәт мэрияләре хезмәткәрләре җавап бирәчәк.

Казан – иң уңайлы шәһәрләр исемлегендә

Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Екатеринбург һәм Түбән Новгород Россиянең яшәү өчен иң уңайлы шәһәрләре булып танылган. Россия Фәннәр академиясенең Урал бүлеге галимнәре Александр Соколов һәм Оксана Руднева әнә шулай дип белдергәннәр.

Галимнәр яшәр өчен уңайлы булган шәһәрләр исемлеген төзегән. Әлеге дәрәҗә 25 төрле күрсәткечләр нигезендә бәяләнгән. Алар арасында да шәһәрдә метро булу, авиаэлемтәләрнең ни дәрәҗәдә җайланганлыгы, шулай ук никадәрле югары уку йорты һәм театр булуы мөһим роль уйнаган. Галимнәр әйткәнчә, Мәскәү рейтингта икенче һәм өченче урыннарны биләгән Санкт-Петербург һәм Казаннан шактый алга бара. Моннан кала, рейтингта Татарстаннан Чаллы да күрсәтелгән. Алар Самара белән 14нче һәм 15нче урыннарны били.

Галимнәр фикеренчә, иң уңайлы шәһәрләр дип Россиянең Европа өлешендә урнашканнары табылган. Алар, транспорт мөмкинлеге яхшырак булганлыктан, тизрәк үсеш ала.

Карлы апрель

→ **Ахыры. Башы 1нче биттә.**

Юл хезмәтенә исә эш җитәрлек. Кичә федераль юлларга 109 кар чистарту техникасы чыккан, бозлавыкка каршы 1 мең тонна катнашма сибелгән. Төбәк дәрәҗәсендәге юлларда 120 берәмлек техника эшли, дип хәбәр итте Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы.

«Казан», «Бигеш» һәм «Бөгелмә» аэропортлары исә штатлы режимда эшләвен дәвам итте. Тимер юл транспортында да тоткарлыклар күзәтелмәгән.

Ә менә таксистлар карлы апрельдән файдаланып калырга ашыкты бугай. Үз автомобильләрен такси хезмәтенә алыштыручыларга бу көнне икеләтә түләргә туры килде. Әйтик, Uber аша такси чакырту гадәти көннәрдә 200 сум булса, кичә ул 500 сумга җиткән иде.

Көнчыгыштан килеп кергән циклон Татарстанда тагын бер-ике көн сакланыр дип фаразлана. Республиканың Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе хәбәр итүенчә, якшәмбедә карлы яңгыр, юлларда бозлавык булуы ихтимал. Ә менә дүшәмбедән көннәр җылыта башларга тиеш. Синоптиклар тагын бер атнадан 17 градуска кадәр җылылык вәгъдә итә.

Табигатьнең начар көне булмый, диләрме әле? Апрельдә яуган карга да сөенә белик, быелгы кышның соңгы карын күреп хозурланып калыйк әле.

2014 елда Европа берлеге илләренә карата санкцияләр игълан ителгәннән соң, тикшерүләр нәтиҗәсендә, Татарстанда тиешле таләпләргә җавап бирмәгән 8 мең тонна продукт ачыкланган. Быел гына да тыелган 3 мең тонна азык-төлекне юк иткәннәр. Читтән законсыз кайтартылган продуктлар күпчелек – Польша алмасы һәм грушасы, Төркия помидоры һәм виноградлы. Бу товарлар, нигездә, республикага Белоруссия аша кергән.

Ашар өчен – ярый, сатар өчен – юк

Законсыз товар әйләнешен, икътисади чикләүләр исемлегенә кергән продуктларны Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә Татарстан таможнясы, Россельхознадзор, Роспотребнадзор идарәләре контрольдә тота. Әлеге мобиль төркем төрле урыннарда даими тикшерүләр уздыра. Роспотребнадзорның Татарстан идарәсендә туклану гигиенасы буенча күзәтчелек бүлеге җитәкчесе Елена Сизова әйтүенчә, күптән түгел Казанда билгеле рестораннарның берсендә Франциядән кайтартылган «Пармезан» сырының контрафактлы партиясе ачыкланган.

– Һәр товарның үз «тарихы», кибет киштәсенә ничек килеп эләккәне турында мәгълүмат булырга тиеш. Әгәр теге яки бу продуктның тиешле документы юк икән, юридик затларга 100 мең сумнан алып штраф яный, – ди Елена Сизова.

Дөрес, чит ил сырын яратып өлгергән кешеләргә үз кирәгенә генә куллану өчен аны билгеле бер күләмдә читтән алып кайту рөхсәт ителә. Ә менә законсыз товарны коммерция максатларында таратучы физик затларга 5-10 мең сум штраф каралган.

– Элек законсыз товар зур сәүдә үзәкләрендә күбрәк ачыкланса, хәзер базарларда, күпләп сату урыннарында ешрак очрый икән. Таләпләргә җавап бирмәгән азык-төлекне икенче кат эшкәртергә ярамый, ул кибетләрдә махсус прессларда изделә, шулай ук каты көнкүреш калдыклары түгелә торган чүплекләрдә юк ителә, – дип аңлатты Россельхознадзор идарәсе җитәкчесе урынбасары Ленар Фәттерахманов.

Татарстан таможнясы Казан һәм Бегиш аэропортыннан кергән товарларны тикшерә. Былтыр таможня хезмәткәрләре 102 613 контрафактлы продукцияне кулланыштан алган. Алар арасында автомобиль запчастьлары, парфюмерия, косметика, уенчыклар, ювелир эшләнмәләре, кием-салым да бар. Ни хикмәт, кеше киемнәрен генә түгел, эт өчен комбинезоннарны да ялганлап сата башлаганнар. Былтырның августыннан Евразия илләреннән кертелә торган мех, күн әйберләренә карата да аерым таләпләр. Хәзер һәр тунда, курткада махсус контроль идентификация билгесе куелган булырга тиеш. 2015-2016 елда таможня тикшерүләре сатуда законлы булуы документлар белән расланмаган 4 мең күн һәм мех эшләнмәсен ачыклаган.

Эльвира МОЗАФФАР.

Кошлар ауларга рөхсәт

Татарстанда 22 апрельдән 1 майга кадәр су кошларын ауларга мөмкин.

Дамир БӘДРИЕВ

vk.com

Киичә «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә бу хәбәрне Татарстан Республикасының тереклек дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе хезмәткәрләре җиткерде.

Көртлек (тетеревь), сусер (глухарь), иртә таңда вальдшнеп һәм Кызыл китапка кертелгән соры казны ату тыела. Шулай ук аккошларны һәм торналарны да ату тыела.

– Кыргый казлар, ата үрдәкне (селезень), көндезге якта вальдшнепны фәкать шома көпшәле мылтык белән генә ауларга рөхсәт. Казны көнөнә – икене, ә ата үрдәкне өчне генә атып алырга мөмкин. Ау этләрен һәм сырлы көпшәле мылтык куллану катгый тыела. Урман җәнлекләреннән: поши, кабан, куян, төлке аулау инде февраль аенда ук туктатылды. Хәзер җәнлекләрнең балалау чоры, шунлыктан ау тыела, – диде идарәнең лицензия бүлеге җитәкчесе Ринат Чиспияков. – Соры каргаларны пневматик мылтык белән дә атырга була, аларга лимит юк. Соры каргалар каз һәм үрдәк ояларындагы йомыркаларны, бәпкәләрне ашап, зур зыян китерә.

Татарстанда Әгерҗе, Азнакай, Әлмәт, Аксубай, Баулы, Алабуга, Мамадыш, Балык Бистәсе, Лаеш, Чирмешән, Биектау,гомумән, 27 районда аучылык җирлекләре бар. Тулы исемлек һәм аучылыкка кагылышлы башка мәгълүматлар белән идарәнең интернет сайтыннан танышырга була. Табигать тыюлыкларында һәм заказникларда ау тыела. Аучылык хуҗалыкларына юллама – 3 мең сум, ә ау гамәлләренә дәүләт пошлинасы – 650 сум.

– Ау кагыйдәләрен бозган өчен физик затларга 5 мең сумга кадәр штраф салына, өч елга кадәр вакытка мылтык та алына. Узган ел язгы ау аралыгында 600 кешегә, гомуми исәптә, бер миллион сум штраф салынды, – дип кисәтте идарәнең тереклек дөньясы объектларына күзәтчелек бүлеге җитәкчесе Радик Мутахаров.

Ринат Чиспияков сөйләгәнчә, республикага су кошлары Урта диңгез буйларыннан һәм Әстерхан якларыннан кайта.

– Кыргый кошлар белән «кош гриппы» да ияреп кайтуы ихтимал, – диде Ринат Чиспияков. – Ветеринария хезмәте саклану чаралары күрә. Аучылык хуҗалыкларында ветеринарлар һәвәскәр аучылар янына килеп, атып алынган кошларны тикшерсә, моңа каршылык күрсәтмәү сорала.

Татарстанда 15 апрельдән 15 июньгә кадәр «Уылдык» («Нересть») чикләве кертелде. Балыкны сәнәгать колачларында тоту шушы вакыт аралыгына туктатылды. Һәвәскәр балыкчыларга да 20 апрельдән 10 июньгә кадәр моторлы көймәләрдә елгага кереп, балык тоту тыела.

– Һәвәскәр балыкчыларга көймәдә ятьмә белән балык тотарга гомумән рөхсәт юк, бары тик кармак белән генә. «Уылдык» чикләве аралыгында елга ярыннан балык тотарга рөхсәт, ләкин кармаклар саны бер кешегә дүрт берәмлектән артырга тиеш түгел, – дип искәртте Радик Мутахаров.

Казанда 24-25 апрельдә Идел буе федераль округы буенча актив гражданнарның һәм коммерциячел булмаган оешмаларның «Сообщество» форумы эшләячәк.

Өйдә күңелсезләнеп утырмагыз

Россия Иҗтимагый палатасы тарафыннан мондый форумнар, традицион рәвештә, һәр федераль округта үткәрелеп килә. Казанда ул тәүге мәртәбә узачак. Быел Ярославль һәм Красноярск шәһәрләрендә оештырылган форумнарда өч меңнән артык активист катнашкан.

Казандагы форум программасына уку-өйрәнү, фикер уртаклашу чаралары кертелгән. Унике яшьтән унсигез яшькә кадәрге актив егетләр һәм кызлар өчен «Сообщество Junior» форматы каралган. Секторара хезмәттәшлек темасы социаль проектларны гамәлгә ашыруда теләктәшләр эзләү алымнарын барлаячак.

Авыл китапханәләренә ярдәм максатында, #АгроМания Бөтенроссия акциясен Казанда да башлап җибәрү ниятләнелә. Узган ел тынгысыз күңелле кешеләр 80 меңнән артык китап җыйган, әлеге мәдәни байлык авыл китапханәләренә тапшырылган. «Сообщество» форумнары үткәндә, Красноярск шәһәрендә – 600, ә Волгоградта 1500 китап тупланган. Казанда да авыл китапханәләре өчен китаплар җыю оештырыла. Форумда катнашу өчен форумсообщество.рф сайтында теркәлү узу зарур.

Яшь гаиләләргә ярдәм кирәк

«Бердәм Россия» фракциясеннән Дәүләт Думасы депутаты Ольга Баталина 23 яшькә кадәр беренче баласы туган гаиләләргә дәүләт аларның ипотекаларын түләргә ярдәм итә алыр иде дигән фикердә тора, дип яза «Татар-информ».

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Дәүләт Думасында хисап белән чыгыш ясаганда, премьер-министр Дмитрий Медведев Россиядә гаиләләргә ярдәм итү дәвам ителергә тиеш, аның өчен яңа чаралар эшләргә кирәк, дип белдергән.

«Чынлап та, 2030 елга кадәр безнең ил демографик авырлыклар белән бәрелешәчәк, бала тудыру яшендәге хатын-кызлар саны кими. Бу шартларда инде балалары булган гаиләләр хисабына гына бала тудыруны тулыландырырга була. Бер үк вакытта яшь гаиләләрдә беренче балаларын тудырыга этәргеч ясарга да кирәк», – дип җиткергән Баталина сүзләрен аның матбугат хезмәте.

Депутат фикеренчә, тәэсир итүче чараларның берсе булып, балалар хисабындагы фатир өлешен түләү торырга мөмкин.

– 23 яшькә кадәр беренче баласы туган гаиләләргә дәүләт ипотекага түләүнең бер өлешен каплап ярдәм итә алыр иде. «Бердәм Россия» партиясе тарафыннан демографик чишелеш юлы итеп, бу тәкъдим ителгән иде, – дип искәрткән Баталина.

Азизәгә уңышлар телик

Бүген Архангельскида «Урман патшабикәсе –2017» дигән Бөтенроссия конкурсының финалы уза.

Анда урман хуҗалыгы тармагында эшләүче һәм уку йортларында белем алучы яшьләр һәм эшчеләр катнаша. Россиядә Экология елы буларак, шул темага кагылышлы проблемалар да күтәреләчәк. Әлеге бәйгедә Казан дәүләт аграр университеты студенты Азизә Фазылова да катнаша. Аңа уңышлар телик!

Ветераннарга бушлай юридик ярдәм

Татарстанның Юстиция министрлыгы 27 апрельдә Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм аларның гаиләләренә бушлай юридик ярдәм күрсәтү оештыра.

Чарада Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге, Федераль салым хезмәтенең Татарстан идарәсе, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе, Татарстанның медик-социаль экспертиза баш бюросы, төрле министрлыклар, Дәүләт торак инспекциясе, Казан Башкарма комитетының Җир һәм милек мәсьәләләре, шулай ук Торак сәясәте комитеты вәкилләре, адвокат, нотариуслар катнашачак.

Казанлылар бушлай юридик ярдәм алу өчен 27 апрельдә сәгать 10.00-13.00гә кадәр Халыклар дуслыгы йортына (Казан, Павлюхин ур., 57нче йорт, 1 к) мөрәҗәгать итә ала. «Павлюхин урамы» тукталышына кадәр 4, 5, 25, 43, 68, 71, 77нче автобуслар бара. Әлеге чара турында тулырак мәгълүматны **(843) 223-02-13** телефоны аша белешергә була.

УЯУ БУЛ!

Быелның өч аенда алдакчы-мошенниклар Казан халкының 12 миллион сум тирәсе акчасын үзләштергән. Бу – талап түгел, ә кешеләр үз куллары белән чыгарып тоттырган, банк картасыннан яки телефоннан күчергән акчалар.

Дамир БӘДРИЕВ

s.0542.ua

– Башкалада быелның өч аенда алдап-йолдап акча алуның 689 очрагы теркәлде, шуның 443е – кәрәзле телефон һәм интернет челтәре аша, – диде матбугат конференциясендә Казан шәһәре буенча эчке эшләр идарәсе «Московский» полиция бүлегенең мөлкәти җинаятьләрне ачу бүлеге җитәкчесе Айдар Кначуков.

Күптән түгел Казанның Мәскәү районында яшәүче 91 яшьлек әби таныш булмаган кешегә 42 мең сум чыгарып биргән. «Оныгың юл-транспорт һәлакәтенә юлыкты. Полициядән алып калу өчен тиз генә акча тапшырырга кирәк», – дип шалтыратканнар аңа. Монысы мошенниклар куллана торган иң «популяр» алым. Айдар Кначуков сөйләгәнчә, башта бер кеше, бик дулкынланган тавыш белән, «фаҗига» турында хәбәр итә икән. Шуннан соң ныклы тавышта сүзне «полиция хезмәткәре» дәвам итә, булышырга ышандыра. Баланың яки оныгыңның бәладән йолып калу өчен ни генә эшләмәсәң?! Мошенниклар әнә шулай кешеләрнең күңел кылларында оятсызларча уйный.

Безне 70 процент очракта Татарстаннан читтәге төбәкләрдән шалтыратып алдыйлар икән.

– Банк картагыз томаланып калды, аны ачу өчен фәлән телефонга шалтыратыгыз, дигән SMS хәбәр килсә, ул номерны һич кенә дә җыя күрмәгез. Кайсы банк белән эш йөртсәгез, шул банктагы үзегез белгән телефонга гына шалтыратыгыз, – дип кисәтте Казан шәһәре буенча эчке эшләр идарәсенең мошенниклыкка кагылышлы җинаятьләрне ачу бүлеге җитәкчесе Илдар Вафин.

Интернет-кибетләрдән товар китерткәндә дә сак булырга кирәк.

– Бер көнлек сайтларда бик арзан бәяләрдә товар исемлеге куела. Тартмага гап-гади елга комы яки макулатура тутырып җибәрелгән фактлар бар. Почтада акча түләгәнче башта тартманы ачып, товарны тикшерегез. Почта чыгымын түләргә тиешле булса, түләрсез. Бу, һәрхәлдә, 30-40 мең сум түләп, өйгә ком тутырылган тартма күтәреп кайтып китү түгел. Кабатлап әйтәм, тартманы өйгә кайткач түгел, ә почтада яки кибеттә ачып карагыз, – дип киңәш итте Айдар Кначуков.

Казанның Мәскәү районында яшәүче 75 яшьлек ханым быелның 29 мартында полиция бүлегенә гариза керткән. Әлеге хатынга урамда бер ир-ат арзан бәядән кием сатып алырга тәкъдим иткән. Тегеир: «Туганым каты авырый, кыйммәтле дарулар кирәк. Бөтен акчаларымны дарулар алырга тотып бетердем инде», – дип мескенләнеп сөйләгән. Хатын моны кызганып, фатирына алып кайткан.

– Соңыннан банкка чыкканнар. Беренче һәм икенче банкта җитәрлек кадәр акча булмаган. Өченче банкта шул Мәскәү районында яшәүче хатын Сызрань шәһәре мошенникына 1 миллион 140 мең сум акчасын үз куллары белән тапшырган. Әлеге мошенник апрель аенда полиция тарафыннан тоткарланды, – дип, гыйбрәтле хәлне сөйләп бетерде Айдар Кначуков.

Казан федераль университетының дефектология һәм клиник психология кафедрасы доценты Инна Кротова әйткәнчә, өлкән буын вәкилләре мошенниклар коткысына аеруча бирешүчән.

– Өлкәннәр әдәп-әхлак тәрбиясендә үскәннәр. Алар ялганны белмиләр, һәр сүзгә ышаналар. Өлкән кешеләр игътибарга һәм аралашуга мохтаҗ. Сөйләшкән кеше белән чишелеп, сөйләшеп китәләр. Өлкәннәрнең хәлләрен даими белешеп тору мәслихәт. Бүгенге җәмгыятьтә, әлбәттә, бүрегә әйләнергә кирәкми, ләкин уяу булу зарур, – диде Инна Кротова.

КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

ИСЕГЕЗДӘ ТОТЫГЫЗ

✓ Өегезгә яки фатирыгызга таныш булмаган кешеләрне кертмәгез.

✓ Социаль һәм ашыгыч хезмәтләр вәкилләре мөрәҗәгать итсә, документларын карагыз. Учреждениеләренә шалтыратып сорагыз. Социаль органнар хезмәткәрләре фатирларга йөреп акча алмаштырмый.

✓ Акчага бозымны бетерәм, дип әйтүчеләргә ышанмагыз.

✓ Туганыгыз автоһәлакәткә яки полициягә эләкте, дип шалтыратсалар, каушап калмагыз. Туганыгызның телефонын җыегыз, әгәр җавап бирмәсә, полициядән вакыйганы белешегез. Мин – полиция хезмәткәре, адвокат, юрист, дип таныштырган чит кешеләргә акча чыгарып тоттырмагыз, акча күчермәгез.

✓ Интернет аша товар сатканда яки алганда банк картасына бәйле булмаган телефон номерыгызны языгыз. Сатып алучыга банк картагызның номерын, кодын һәм башка документлар мәгълүматларын бирмәгез. «Мобиль банк» яки «онлайн» банк аша акча күчергәндә, алучы кешенең банк картасы саны гына кирәк. Акча күчкәнлекне раслар өчен бернинди код та кирәкми.

✓ Билгесез абоненттан-адресаттан теге яки бу интернет чыганакка күрсәтелгән хәбәр килсә, әлеге «күрсәткеч» артыннан иярмәгез. Телефоныгызга вируслы программа үтеп керергә мөмкин. Номерыгыз банк картагызга бәйле булган очракта, барлык акчагызны «чистартулары» ихтимал;

✓ Банк картагыз томаланып калды, дип хәбәр бирсәләр, фәкать банк картагызга язылган «кайнар элемтә» телефонына гына шалтыратыгыз. Банк картасын көйләү бары тик банк учреждениесендә һәм шәхесне раслый торган документларны күрсәткәннән соң гына башкарыла.

Милләтебез белән кызыксыну арта

Татар халкын юкка гына бөек милләт димиләр шул. Үзе батыр, үзе кыю, үзе горур халык белән соңгы елларда Европа галимнәре дә ныклап кызыксына башлаган. Оксфорд университетында 7-8 апрель көннәрендә узган «Татарлар – дөнья тарихында» дигән халыкара фәнни конференциядә сүз шул хакта барган. Анда төрле ил галимнәре бергәләп язган «Дөнья тарихында Алтын Урда» дигән китапны тәкъдим итү булган.

tatar-congress.org

Әлеге конференциядә катнашкан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры, тарих фәннәре докторы Рафаэль Хәкимов Оксфордка зур галимнәрнең нәкъ менә шул темасы ныклап өйрәнү өчен махсус җыелуын әйтте. Әлеге китап һәм җиде томлы «Татар тарихы» китабы ТАИФ акционерлык оешмасының матди ярдәме белән инглиз теленә тәрҗемә ителгән. Журналистлар белән очрашуга тарих фәннәре докторы Радик Салихов, Миркасыйм Госманов исемендәге Алтын Урда һәм татар ханлыклары өйрәнү үзәге җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты Илнур Миргалиев, тарих институтының гыйльми секретаре, тарих фәннәре кандидаты Бәхтияр Измайлов та килгән иде.

Президент Рөстәм Миңнеханов Европада беренче һәм икенче бөтендөнья сугышларында һәлак булган татар сугышчыларының каберләрен дә эзләп карарга кушкан булган.

– Без бу эшне республика зиратларын өйрәнүдән башлаган идек. Күп кенә кабер ташларын ачыкладык. Ә иртәгә Германиягә сәяхәткә кузгалабыз, – диде Тарих институтының фәнни эшләр буенча директор урынбасары Радик Салихов. – Башта Көнбатыш Германиягә барырга җыенабыз, аннары башка якларына да. Анда милләттәшләребез күпләп ятып калган. Әлеге проект өч-дүрт елга сузылып, хәбәрсез югалганнарның исемнәрен туганнарына кайтарып бирергә җыенабыз.

Бүгенге көндә мәрҗаниләләр бар дөньяга танылган атаклы тарихчылар белән бергәләп «Европада татар тарихы» дигән зур хезмәтне нәшер итәргә әзерлиләр.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Илдар Сәгъдәтшин:

«Татар китабы сезгә үзе киләчәк»

Татарстан китап нәшрияты турындагы хәбәрләр соңгы арада әледән-әле яңгырап тора. Бер карасаң, данлыклы Матбугат йортында китап кибете ачылу, икенче карасаң, интернетта «Татар әдәбияты үзәге» дип исемләнгән портал булдыру, өченче карасаң... Хәер, санап торасы бармыни инде, хәтта Путин кулында да ТКН чыгарган китап ич – Тукайның «Шүрәле»се. Шул ук вакытта: «Төбәкләрдә татар китаплары сатыла торган кибетләр юк. Татар китапларын кайдан алырга?» – дигәнрәк сораулар да ишетелгәләп куя. Мәсьәләгә ачыклык кертү йөзеннән, нәшриятның генераль директоры Илдар Сәгъдәтшинга берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

– Татарстан китап нәшрияты елына күпме китап бастырып чыгара? Нинди жанрлар үтемле исәпләнә?

– Татарстан китап нәшриятында елына якынча 200ләп китап басылып чыга. Бу үзе үк дәүләтнең әдәбиятыбызга булган мөнәсәбәтен чагылдыра. Дәүләт хисабына китаплар чыгару, тарату, авторларга гонорар түләү тәҗрибәсе бүген Татарстан, Башкортстан, Чувашия, Якутия кебек берничә республикада гына сакланып калган. Нәшер ителгән китаплар арасында дәреслекләр дә, фәнни хезмәтләр дә, һәртөрле белешмәләр дә, матур әдәбият әсәрләре дә бар. Китапларның 60 процентын – татар телендә, калганнарын башка, чит телләрдә чыгарабыз.

Ә иң үтемлесе – төрле яшьтәге балалар өчен китаплар. Бу бездә генә түгел, башка халыкларда да шулай. Һәр ата-ана үз баласының акыллы, тәрбияле булып үсүен, аның чын шәхескә әйләнүен тели. Шулай ук классик язучыларның әсәрләрен дә күп сорыйлар. Һәр басманың үз укучысы бар инде.

– Китапка караш бүген бер төрле генә түгел. Аңа рухият игезе итеп тә, товар итеп тә карау бар. Ә сезнеңчә, нәрсә ул китап?

– Әдәби әсәрләр, китаплар ярдәмендә тәрбияләнеп ничәмә-ничә буын үз асылын саклады, рухи нигезен ныгытты. Әдәби китаплар яшь буынны ана телендә камил сөйләшергә, фикерен матур һәм ачык итеп җиткерә белергә, милли үзаңны сакларга һәм ныгытырга, рухи кыйммәтләр тупларга булыша. Гомумән, камил шәхес формалаштыруны китаптан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Матур әдәбият, чыккан китапларның сыйфаты һәм саны телнең дә, халыкның да яшәешен аермачык күрсәтеп тора. Шуңа күрә матур әдәбият һәм язучы хезмәте электәлән үк хөкүмәтнең дә, халыкның да игътибар үзәгендә. Әдәбият ул – җәмгыятьнең рухи һәм әхлакый барометры дисәк тә буладыр.

– Китап сәүдәсе бик катлаулы, җитди чыгымнар таләп итә торган нәрсә. Нигездә, 2-3 мең данәдә нәшер ителгән татар китаплары бүген үз-үзен аклыймы?

– Күп еллар дәвамында Татарстан китап нәшриятына социаль әһәмияткә ия әдәбият чыгару өчен Татарстан казнасыннан субсидия рәвешендә акча бүленеп бирелә. Мәсәлән, 2016 елда 226 китап дөнья күрсә, шуларның 110ы дәүләт хисабына нәшер ителгән. Ул китапларның 85 проценты республика

китапханәләренә һәм татарлар күпләп яшәгән төбәкләргә таратыла. Шул рәвешле, чыгымнарның аклану мәсьәләсе беркадәр хәл ителә. Аннан соң, Казанда өч кибетебез эшләп килә. Һәртөрле әдәби чараларда катнашып та китап сату оештырабыз. Китапларны халыкка җиткерүнең яңа юлларын табарга тырышабыз.

– СССР чорында хәтта авылларда да китап кибетләре була торган иде. Бүген татар китабын район үзәкләрендә сатып алу да мөмкин түгел.

– Элек китап сәүдәсе белән шөгыльләнүче оешма аерым булган. Бүгенге чорда ул үзен аклар идеме икән, төгәл генә әйтү авыр. Безнең өчен бүген иң мөһиме – китаплар нәшер итү. Әгәр китап бар икән, аны алучы табылачак. Шулай да без башкаладан читтәрәк яшәүчеләрне игътибарсыз калдырмаска тырышабыз. Әйтеп үтүемчә, район китапханәләрендә безнең китапларны рәхәтләнеп алып укырга мөмкин. «Татмедиа» белән берлектә оештырылган «Китап бәйрәме» проекты нигезендә, республика районнарына чыгып, әдәби очрашулар үткәрәбез. Бу эшкә язучылар да, дәреслек авторлары да бик теләп катнаша. Авторларның үзләре белән аралашкач, китап алучылар да күп була.

– Миннән: «Сезнең китапларыгызны кайдан алырга була?» – дип сораучылар бик күп. Күбесе чит республикалардан. Моңа, гадәттә, берничек тә җавап бирә алмыйм. Һәм үземә бирелгән сорауны сезгә юллыйм: чит төбәкләрдә татар китапларын кайдан сатып алырга мөмкин?

– Чит төбәкләрдә яшәүчеләрнең ихтыяҗын күз уңында тотып, без интернет-кибет булдырдык. Аңа шушы адрес буенча керергә була – www.tatkniga.ru. Заманча технологияләр буенча эшләнгән бу кибеттә яңа чыккан һәр китап белән танышырга, сатып алырга мөмкин. Анда компьютердан да, кесә телефоныннан да керергә була. Шулай ук социаль челтәрләрдә үз төркемнәребез бар. Китап сөючеләр шул төркемнәрдә теркәлсә, татар әдәбияты яңалыкларыннан читтә калмаячак. Бу чит төбәкләрдә яшәүчеләр өчен дә, татарстанлылар өчен дә бик җайлы. Теләгән китабыңны кулга төшерү өчен хәтта өеңнән дә чыгып торасы түгел. Бары тик заказ гына бир – ул сиңа үзе киләчәк.

Бүген сайтка тәүлек әйләнәсенә 200-300ләп кеше керә. Әле бу реклама булмаган килеш шулай, моңа кадәр бар көч сайтны булдырыгa, камилләштерүгә юнәлдерелгән иде. Хәзер сайт дөньяның теләсә кайсы онлайн китап кибете белән чагыштырырлык дәрәҗәдә. Киләчәктә сайтны таныту өлкәсендә дә беркадәр көч салсак, татар китапларын кайдан табарга дигән сорау тумас.

– «Татар әдәбияты үзәге» порталы турында әйтүегез инде. Анда бик уңайлы китапханә, электрон китап кибете дә бар бит әле...

– Китапханәгә дөньяның теләсә кайсы почмагыннан ирекле рәвештә керергә мөмкин. Электрон китаплар компьютерда да, телефоннарда да, уку җайланмаларында да бик уңайлы ачыла. Арада матур әдәбият та, мәктәпләр өчен интерактив дәреслекләр дә бар. Белем бирү процессында, фәннәргә кызыксыну уяту җәһәтеннән, укытучыларга аларны куллану отышлы булыр дип ышанабыз.

Ә инде электрон китап кибете узган елның җәендә эшли башлады. Бүгенгә кадәр анда 35 мең кулланучы кергән. Шуларның 2 меңе китап сатып алган. Электрон китапларның бәясе күпкә арзанрак һәм аны чит илләрдә дә сатып алырга була. Кәгазь китапка заказ биргәндә, почта чыгымнары да ярыйсы ук кыйммәт була. Ә электрон китапның андый мәшәкате юк, шуңа күрә аның бәясе үзгәрми. Шул җәһәттән бик уңайлы.

– «Китап бәяләре кыйммәтләнде, кайберләре 380 сум тора», – дип зарланучылар да бар...

– Тирә-якка күз салсагыз, акрынлап кына бөтен нәрсәләргә дә хак арта. Безнең очракта кәгазьгә дә, типография буяуларына да, башкасына да. Ә җиһазлар, җайланмалар чит илдән кайтартылган. Аларны карау өчен дә, төзәтү өчен дә доллар белән түләргә туры килә. Хәтта гади генә бензин һәм электр бәяләре дә бер урында тормый. Шулай булгач, бәяләрнең артуы безнең эшчәнлеккә дә йогынты ясый. Китап җитештерү бәясе күтәрелә. Шулай да мин татар китапларына хак чамасыз югары дип әйтә алмыйм. Шул ук Мәскәүдә чыккан каты тышлы китапларның уртача хакы күптән инде 600 сум тирәсендә йөри. Без үзкыйммәтеннән бик күтәрмәскә тырышабыз.

– Татарчага тәрҗемәләр юк дигән сүзләрне дә соңгы арада еш ишетергә мөмкин. Пушкин шигырьләре белән дә татарча танышкан кеше буларак, мин, әлбәттә, белӛм аларның бар икәнен. Г. Маркесның «Ялгызлык» романы, Д.Лондон, Ж.Верн һ.б. әсәрләре. Дөнья классикасының искиткеч тәрҗемәләре бар бездә. Шуларны кабатлап чыгару, хәтердә яңарту теләге юкмы?

– Бу хакта күптән уйлыйбыз. Әйтик, шул ук «Белмәмеш» тә («Незнайка») «Гарри Поттер»дан ким укылмас иде. Ул чорда чит ил яки рус әдипләрен дә безнең зур язучыларыбыз, әдәбиятыбызның классиклары тәрҗемә иткән бит. Шулай ук заманында бик популяр булып та, хәзер онытыла төшкән язучыларыбыз да бик күп икән. Бүгенге заман укучысы ул әсәрләр белән бөтенләй таныш түгел диярлек. Ә бит кайберләре шулкадәр актуаль, бүген язылган шикелле. Бу юнәлештә эшлисе эшләребез бихисап әле. Гомумән, киләчәккә хыяллар бик күп.

– Якты хыялларыгыз чынга ашсын дип әйтергә генә кала инде.

Әңгәмәдәш –
Марат КӘБИРОВ.

ПОЧТАДАН

Иганәчеләр ярдәм итсен иде

Баулы шәһәрендәге «Березка» инвалидларны тернәкләндерү үзәгендә Татарстанның төрле почмакларыннан килгән кешеләр дәвалана. Үземә дә анда булырга туры килде.

Безнең тәннәрне генә түгел, күңелебезне дә дәваладылар монда. Төрле шәһәрләрдән килгән үзешчән коллективлар чыгыш ясады. Баулы шәһәренең 7нче урта мәктәбе укучылары, Актүбә шәһәреннән килгән физик яктан мөмкинлекләре чикләнгән балалар, Бөгелмә шәһәреннән үзешчән коллективлар дисеңме... Лениногорскидан килгән музыка коллективы чыгышы аеруча истә калды. Ансамбль җитәкчесе Равил Гыйматдинов баянда, гармунда уйнап биетте, җырлатты. Фәния Латыйпова үзенең моңлы җырларын бүләк итте. Валентина Модина рус, чуваш җырларын да башкарды. Нәфис сүз остасы Гәүһәр Гыйльфанова концертны кызыклы вакыйгалар сөйләп җанландырды.

«Березка» үзәгендә шундый җылы мохит булдыруда беренче чиратта директор Ландыш Гарифуллинаның өлеше зур. Ул үзе дә тернәкләнүчеләргә ягымлы мөнәсәбәттә, үз булмәсенә кергәнче, башта барысы белән елмаеп исәнләшә. Мәдәни чаралар оештыручы Владимир Альметин иртә белән үк көн дәвамында нәрсә буласы белән таныштыра, кичке ялны оештыра.

Шунысы борчый: «Березка» тернәкләндерү үзәге 1970 елларда төзелгән. Бирелӛ инвалидлар өчен бөтен уңайлыклар да тудырылган анысы. Пандуслар, стенада инвалидлар өчен махсус тоткычлар да бар. Кичен ял итүчеләр җыела торган бүлмә бик кечкенә. Концертлар узганда, һәр кешегә дә урын җитми, халык күплектән тын алу авырлаша, йөрәк авырулы кешеләр чыгып китәргә мәҗбүр булалар. Шушы турыда директорга да әйтеп карадым, тик финанс мөмкинлекләре булмау сәбәпле, бу хакта хыяллана да алмыйбыз, дип җавап бирде. Ял итү бүлмәсеннән тыш, тернәкләнүчеләр яшәгән кабинетларны ремонтлыйсы бар. Бу хакта иганәчеләр кайгыртса, яхшы булыр иде. Тернәкләнүчеләр арасында сугыш ветераннары, эш урынында сәламәтлегенә зыян килгәннәр дә бар. Әлеге кешеләргә ярдәм итү зур савап булыр иде.

Илдус ШӘЙХЕТДИНОВ,
Баулы районы,
Исергәп авылы.

сәхнә

Сандугачың ни әйтергә тели?

Бу атнада Рәшит Ваһапов исемендәге Халыкара татар җыры фестиваленең 2017 елгы яшь башкаручылар конкурсының җиңүчеләре билгеле булды. Быел да конкурс, сәләтле яшьләр арасында зур кызыксыну уятып, рекорд куйды. Мәсәлән, 2013 елда әлеге бәйгегә – 33, 2015 елда 97 гариза килгән булса, быел аларның саны 122гә җиткән. Жюри бер тавыштан бәйгенең иң югары бүләге – Гран-прины Казан мәдәният институты студенты Рәнис Габбазовка бирде. Барлык лауреатлар 15 майда Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында үтәчәк гала-концертта бүләкләнәчәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Эксперт комиссиясе гариза бирүчеләрнең 115ен жюрига тәкъдим иткән иде. Конкурсның ике туры Уфада һәм Казанда үтте. Йомгаклау туры да узган атна ахырында Татарстан башкаласында узды.

Проектның авторы һәм җитәкчесе, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рифат Фәттахов әйтүенчә, быел Башкортстаннан ун катнашучы тәкъдим ителгән. Шуңа күрә жюри әгъзалары арасында күрше республикада яшәп иҗат итүче күренекле артистлар һәм педагогларның булуы да гаҗәп түгел иде. Бәйге дүрт номинация – «Халыкчан башкару», «Академик вокал», «Эстрада җыры», «Вокал ансамбль» буенча барды.

– Бөтен җаваплылык белән әйтә алам: безнең конкурста объектив бәя бирелә. Биредә җиңеп чыккан талантлы яшьләрнең татар сәхнәсендә үз урыннарын алуы шул хакта сөйли, – диде Рифат әфәнде.

Быелгы сайлап алу турларының тагын бер үзенчәлеге – дөньякүләм танылган легендар җырчы Ренат Ибраһимовның жюри рәисе итеп билгеләнүе. Моңа кадәр әлеге дәрәҗәле һәм җаваплы вазифаны легендар җырчыбыз Илһам Шакиров башкарып килде.

– Казаннан егерме ел элек киткән идем, күрәсең, кире кайтырга вакыт җиткәндер. Ул мине зур үзгәрешләр белән каршы алды. Татарстанда җырчылар да бик күп, ялгышмасам, меңнән артып киткәндер. Хәзер инде сан артыннан кумыйча, сыйфатны алга чыгарырга кирәк. Әлеге конкурс та профессионалларны ачыкларга ярдәм итәр дип ышанам, – диде яңа жюри рәисе.

– Мин конкурсның беренче көннәреннән бирле үк жюрида катнашам. Кечкенә генә булып башланган бәйгенең офыклары киңәйде. Чыгыш ясаучылар да елдан-ел арта. Шуны әйтәсем килә: башка бик күп конкурсларда яшьләрне бәяләргә туры килә. Аннан соң да аларның тормышларын күзәтәм. Рифат продюсер буларак, балаларын үз канаты астына алып, зур сәхнәгә чыгара. Әлеге фестиваль шуның белән аерылып тора, – дип бәяләде күренекле композитор Резеда Ахиярова Рәшит Ваһапов исемендәге Халыкара татар җыры фестиваленең эшчәнлеген.

Зөһрә Сәхабиева:

«Салих Сәйдәшевнең кем икәнлеген белмәүче җырчылар бар»

Жюри әгъзаларының сүзләренчә, быелгы конкурска да берсеннән-берсе сәләтле, матур тавышлы егет һәм кызлар килгән. Әмма аларның катнашучыларга карата теләк-тәкъдимнәре дә шактый җыелган иде. Мәсәлән, Резеда Ахиярова җыр авторларының дөрес итеп әйтелмәве турында әйтсә, Нәҗиб Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең музыкаль театры кафедрасы мөдире, профессор Әлфия Җәббарова, башкаручы музыка ярдәмендә билгеле бер идеяне җиткерергә тиеш, дип саный.

– Сезнең тавышларыгыз сандугачныкыдай шулкадәр матур, чишмәдәй чылтырый. Әмма күпчелек очракта сандугачның тавышын ишетәбез, ә аның нәрсә әйтергә теләвен аңлап бетерә алмыйбыз. Киләчәктә бәйгедә катнашучыларга теләгем бар: үз сандугачыгызның нәрсә әйтергә теләвен җиткерсәгез иде. Тавыш – тавыш өчен генә түгел, ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан сәхнәдә нәрсәдер әйтер, җиткерер өчен бирелгән. Киләчәктә сез – безнең милли статусны күтәрергә тиешле кешеләр, шуңа күрә һәр яктан белемле, милли лидерлар булырга омтылыгыз, – дип мөрәҗәгать итте профессор залда утыручы яшьләргә.

Ә менә Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхабиеваның чыгышын тыңлаганнан соң, Резеда Ахиярова бөтенләй тынсыз калды. «Андыйлар да бармыни?» – дип чиксез гаҗәпләнде ул.

– Килешәм, җырчы шәхес булырга тиеш. Моның өчен аңа төрле яктан үсәргә кирәк. Иң элек музыка тарихын өйрәнергә кирәк. Кайвакыт Салих Сәйдәшевнең кем икәнлеген белмәүчеләр дә очрый. Бервакыт миңа шундый сөйләшү шаһиты булырга туры килде. Бер җырчы икенчесеннән: «Салих Сәйдәшевнең телефонын бирмәссезме икән. Миңа аның көе бик ошады, җырын сорыйсым килә», – дип мөрәҗәгать итте. Классик композиторыбызның дөньядан киткәнлеген дә белмәгән кеше аның кайда туганлыгын, нинди әсәрләр иҗат иткәнлеген дә белми бит инде. Җырчы булырга җыенучылар арасында менә шундыйлар да бар хәтта. Андыйлар кулына калырга язмасын, – диде Зөһрә Сәхабиева.

Татар хорлары дирижеры, Татарстанның халык артисты Венера Гәрәева исә репертуардагы горизонт җитмәүгә басым ясады. Аның әйтүенчә, бәйгедә катнашучылар һаман бер төрле халык җырларын, бер үк композиторларны тәкъдим итә. Ел да бер үк төрле җырлар кабатлану татар музыкасының тарлыгын күрсәтә, ди ул.

– Безнең искиткеч композиторларыбызның фамилияләре төшеп калды. Халык җырларының репертуарын да киңәйтергә кирәк. Без Себер, Касыйм татарлары дибез. Һәр төбәккә генә хас үз стиле бар. Менә шул төбәкләрдәге җырларны барлап, алып килергә кирәк. Татар теле бик бай бит ул. Менә быел «Кар суын» алып килделәр. Афәрин! – диде.

Раил Садриев:

«Сез әле мине белмисез...»

Чыннан да, тамашачы күңелендә көлкеле образлар тудыруы белән урын алган Буа театры директоры һәм артисты Раил Садриев бөтенләй башка яктан ачылды. Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе сәхнәсендә ул ике сәгатькә якын 36 шигырь һәм поэмадан өзек укыды. Мәдәният казанында кайнаучылар, мондый шигъри моноспектакльләрнең татар сәхнәсендә өч дистә ел булганы юк иде, дип бәяләде.

– Мондый кичә уздыру идеясе беренче тапкыр Камал театры сәхнәсендә Константин Райкинның моноспектаклен карагач туган иде. Аннан соң Беренче каналда шагыйрьләр турында цикл тәкъдим ителде. Шуның да тәэсире булды. Ә инде Сергей Безруковны караганнан соң мин шигъри кичәнең ничек булырга тиешлеген тәгаен күзалладым. Дөрес, бик икеләнеп кенә алындым бу эшкә, хәтта репетиция ясауны да ахырга кадәр суза килдем. Шуңа күрә сәхнәдә кытыршылыклар, кимчелекләр дә булгандыр. Халкыны 1,5 сәгать буена шигырь тыңлатып утыртып булырмы, аларны кабул итәрләрме, юкмы дип шикләнгән идем, – диде ул безгә.

Әмма Раил әфәнденең шикшөбһә, икеләнүләренә урын калмады – тамашачы шигъри спектакльне бик яратып кабул итте. Күңел нәкъ менә шундый кичәләргә сусаган икән бит. Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Ркаил Зәйдулла, Илдар Юзеев, Әнгам Әтнабаев, Илдус Гыйләҗев, Эльмира Җәлилова, Гөлара Шәрипова һәм башкаларның туган тел, милләт язмышы, авыл, үлем, мәхәббәт турындагы фәлсәфи шигырьләрен тыңлаганда, кемдер тирән уйга батты, кемдер моңайды, кайсысыдыр ирен читеннән генә елмаеп куйды, ә кайберәүләрнең күзләре яшьләнде. Үлем турындагы әлешендә гыйбрәтле хикәят мисалында «Бу тормыштан берәүнең дә исән чыкканы юк әле. Дөньядан бер генә нәрсәне дә үзебез белән алып китеп булмый. Шуңа күрә байлык артыннан гына куарга кирәкми» дигән фәлсәфи фикерен дә җиткерде Раил Садриев.

– Сәхнәдә өч ел дәвамында тупланылган шигырьләрне тәкъдим иттек. Шуның биш-алтысы моңа кадәр төрле урыннарда сөйләнелгән иде. Калганнарын кичә өчен махсус ятладым. Шулай шигырьләр ятлый торган гадәтем бар минем. Текстны күз белән истә калдырам, – ди ул.

Кичәнең темалар күчеше вакытында сәхнәне җырчы Илфир Солтанов, скрипкачы Динә Закирова, Башкортстан кунаклары – бертуган Айдар һәм Алмаз Юнысовлар бизәде. Раил Садриев әйтүенчә, мондый әдәби-шигъри кичәләрнең дәвамы киләчәктә дә булачак.

– Курка-курка гына алынгач, гадәттә, беренче коймак төерле була. Шуңа күрә киләчәктә моноспектакльне тагын да камилләштереп, кабат тәкъдим итү теләге бар, – ди ул.

Сәхифәне **Зөһрә САДЫЙКОВА** әзерләде.

Ут күршеләр белән көрештек

МӘДӘНИЯТ

Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театры Камал театрында тугыз спектакль тәкъдим итте. Коллектив төрле жанрдагы спектакльләр алып килгән иде.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

Үзләренең тарихи шәхесләре турында «Каһым түрә» драмасын режиссер Олег Ханов сәхнәләштергән. Каһым Мырзашев турында башкорт халкы бүген дә онытмый. Халык аның турында «Каһым түрә» дигән җыр да чыгарган. Әсәр үз милләтенең данлыклы уллары, батырларын онытмаска өнди сыман.

«Хыялга каршы» спектакле аеруча тетрәндергеч. Анда балалар йортларында тәрбияләнүчеләрнең аянычлы язмышы сурәтләнә. Җиде артист ятимнәрнең фаҗигасен ачып бирә. Бигрәк тә Ильяс ролен башкаручы Артур Кәбиров кимсетелгән ятимне зур осталык белән уйнады. Әлеге балалар йортындагы ятимнәрнең язмышын гына түгел, җитәкче хатын-кызның да аларны кимсетүләрен күреп йөрәк әрни. Тормышта да шундый мәрхәмәтсез директорлар булмас дип кем әйтә ала?! Бүгенге көн өчен әһәмиятле проблема күтәргән автор Айгиз Баймөхәммәтов.

Репертуардагы «Ул бит кичә иде» (Айгөл Әхмәтгалиева) һәм «Мин синең каенанаң булам» дигән комедияләрне дә яратты тамашачы. Беренчесендә ялгызлыктан туйган яшьләр үз парларын яңадан табарга хыяллана. Диләрә белән Әсгат язмышларын әр-яңадан язарга телиләр. Очраклы көрәшү вакытында аларда бер–берсенә карата мәхәббәт хисләре уяна. Тамашачы комедиядә елмаеп-көлеп утырса да, уйнаганда кайбер артистларның шактый гына арттырып җибәрүләрен дә сизә. Комедиядә дә чама хисе югалмаска тиеш шул.

«Мин синең каенанаң булам» спектаклендә Башкортстанның, Татарстанның, Россиянең халык артисты Фидан Гафаровның хатын-кыз ролендә уйнаячагын белгәч, берәз гаҗәпләндергән иде. Әмма спектакль барышында аның артистланып кына хатын-кыз булып уйнавын рәхәтләнеп карыйсың. Каенана Галия Харисовна ролен башкарып, ул кызның сөйгәне Җәмилнең күңелен яулый. Тамашачы да аны, хатын-кыз ролендә булуга карамастан, үзенең яраткан артисты Фидан Гафаров буларак күзәтә.

Француз драматургы Жан Ануй Софоклның борынгы пьесасы нигезендә язылган «Антигона» әсәрен Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштергән. Эдип патша дөнья куйганнан соң, аның ике улы аталарының тәхетен югалтмаска сүз бирләр. Тик өлкәне кечесе Полиникны тәхеткә якын җибәрмәскә дигән уй белән, аны үтерә. Әтиләренең туганы Креон патша була. Ул Полиникның гәүдәсен җиргә күмдермәскә боера. Эдипның кече кызы абыйсының гәүдәсен җиргә күмдерергә йөри. Ул аның нинди зур гөнаһ икәнен аңлый. Ә Креон аны җирләгән кешене үлем җәзасына хөкем итәргә боера. Сәхнәдәге күңелсез декорация, тарихи әсәр, бер карагандa, тамашачыга кызык та тоелмый кебек. Әмма режиссер тарафыннан оста куелышы спектакльне бер сулышта карарга мөмкинлек бирә. Башкортстанның халык, Россиянең атказанган артисты Олег Ханов Креон патша образы аша кайбер явыз бәндәләрнең теләсә кайсы чорда да үз кәнәфие өчен мәкерле эшләргә баруын ачык чагылдыра.

«Йосыф һәм Зөләйха»ның сценарие Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Юныс Сафиуллин тарафыннан аңлаешлы итеп язылуы белән җәлеп итә.

Гастрольләрнең соңгы киче театральләштерелгән тамаша белән тәмамланды. Артистларның өлкәннәре дә, яшьләре дә һәр яктан талантлы икәнлекләрен күрсәттеләр.

Төрки халыкларның XIII Халыкара «Нәүрүз» театр фестивале быел 5-10 июньдә узачак. Анда 17 театр коллективы катнаша. «Нәүрүз»нең максаты – төрки халыкларның мәдәни һәм рухи бәйләнешләрен ныгыту.

Камаллылар кунак каршылый

Театр директоры Илфир Якупов әйтүенчә, фестивальнең репертуары үзенең төрлелеге белән аерылып тора.

– Чит ил классикасы да, этник кыйссалар да, заманча драматургия дә күрсәтеләчәк. Без спектакльләр белән күбрәк тамашачыны таныштырырга телибез, – диде ул.

Фестивальнең бюджеты – 5 миллион сум. Билет бәяләре – 150-200 сум.

– Быелгы «Нәүрүз» Якутия театр сәнгатенә багышлана. Аннан дүрт театр килүе көтелә. Аларның театрлары кызыклы. Башкаларга да кызык булыр. Алардан өйрәнергә була, – ди театрның баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев.

Быел төрекләр, кыргызлар, төрекмәннәр, әзәрбайҗаннар кайбер сәбәпләр аркасында килә алмый. Башкаладан читтә булган Татарстан театрларыннан әлмәтләр генә сайлап алынган. Алар «Качаклар» спектаклен күрсәтәчәк. Тәнкыйтьче Нияз Игъламов фикеренчә, фестивальдә беренче тапкыр катнашучы Саха яшь тамашачы театры да кызыксыну уятырга тиеш. Аларның конкүреше, мәдәнияте үзенчәлекле.

Балкарларның 2005 елдан бирле «Нәүрүз»дә катнашканы юк иде. Быел алар да килергә теләк белдергән. Спектакльләр Камал, Тинчурин исемендәге, Казан дәүләт Яшь тамашачы, «Әкият» курчак театры биналарында күрсәтеләчәк. Эстония театры «Нәүрүз»дә кунак буларак катнаша.

Фестивальне оештыручылар – Россия һәм Татарстан Мәдәният министрлыклары, Россия һәм Татарстан театр эшлеклеләре берлекләре, Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.

Люция ГАЛИМҖАНОВА.

«Казан» биючеләре
Бөек Ефәк юлы буйлап сәяхәт итә

17-18 апрель көннәрендә Казан халкы бию тылсымы ярдәмендә Болгар ханлыгы, Кытай, Мисыр, Урта Азия, Һиндстан, Кавказ, Венеция, Осман ханлыгы кебек данлыклы дәүләтләр буйлап сәяхәт итте. 20 еллык юбилейлары хөрмәтенә «Казан» бию ансамбле «Бөек Ефәк юлы» дигән спектакль тәкъдим итте.

Ефәк юлның тарихы безнең эрага кадәр II гасыр чорына барып тоташа. Заманында ефәк алтыннан да кыйммәтрәк бәя йөрткән. Шуңа да Ефәк юлы дистәләгән дәүләтне сәяси, мәдәни, сәүдә җепләре белән бәйләгән. Спектакльдә тарихи фактлар әкияти геройлар белән үрелеп бара. Кытайның ефәк туку серләрен белгән кызыл ханбикәсен Византия императоры урлап китә. Дошман һөҗүме вакытында ханбикә үз рәсеме төшерелгән кульяулыгын югалта. Бу ефәк кульяулык Фарсы принцы кулына килеп ирешә. Ул Кытай ханбикәсенә гашыйк булып, урау юллар аша аны эзләргә чыгып китә. Спектакльдә төрки халыкларының әкият персонажлары да еш очрый. Көтмәгәндә тамашачы залыннан килеп чыккан Хуҗа Насретдин халыкны эчләре катканчы көлдерә. Берәз вакыттан соң, ут янган каурыйларын җилфердәтеп, сәхнәгә сәмруг кошлары чыга.



Ансамбль әлеге спектакльне Мәскәү режиссеры, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Вячеслав Архипов белән берлектә эшли. Бу – режиссерның Казандагы икенче эше. Биючеләрнең профессиональлеге бер кат сокландырса, спектакльнең техник яктан камиллеге, Алинә Шәрибҗанова, «Фәридә-Алсу» дуэты башкаруында җырлар йөрәккә бәлзәм булып ята.

«Казан» бию ансамбле сәнгать җитәкчесе, Татарстан Республикасының халык артисты Чулпан Закирова «Шәһри Казан» хәбәрчесенә труппаның ни өчен нәкъ менә шушы чорга тукталуы турында сөйләде.

– Бу – бай тарихлы, сәнгать өчен кызыклы вакыт. Аз гына үзебезнең фантазиябезне кушып, шушы чорны бүгенге көн призмасы аша күрсәтергә тырыштык. Борынгы Болгар дәүләтенең чәчәк ату чоры да бит әле бу. Кемдер тамашаны әкият буларак кына кабул итсә, кем өчендер ул тарихи кыйммәткә ия. Һәр тамашачы спектакльдә үзенең сорауларына җавап тапкандыр, – диде ул.

Спектакль ике көндә дә аншлаг белән барды. Бу исә 20 еллык тарихы булган ансамбль рәхмәтле тамашачысын тапкан дигән сүз. Шуңа да карамастан, республика мәркәзе булып торган труппаның бүгенгәчә әле үз сәхнәсе юк. Бу исә спектакль куйган вакытта техник кыенлыклар да тудырган.

– Спектакль куйган вакытта үз сәхнәбез булмавы иң кыен әйбер иде. Әсәрне сәхнәләштерү бер ай гына вакытны алмый. Бер көн эчендә чит сәхнәгә килеп кереп, күп уйланылган, тырышкан әйберләрне тормышка ашырып булмый. Үз сәхнәбез булса, без тагын да күбрәкне булдырыр идек, – ди Чулпан Закирова.

Бөек Ефәк юлы аша сәяхәт итәргә теләүчеләрне ансамбль 21-22 май көннәрендә кабат Камал театры сәхнәсендә көтә. Билетлар инде сатуда.

Алисә САБИРОВА.

ШИГЫРЬ ТӘМЕ

Салават Әбүзәровның «Гамәл дәфтәре» китабын укыгач туган уйлар

Роберт МИҢНУЛЛИН,
Татарстанның халык шагыйре

Талантын, шигъри куәсен чамалар өчен, миңа шагыйрьнең «аһ!» итәрлек берничә шигыре дә җитә. Әгәр дә шул берничә шигыре бар икән, димәк, ул – Минем Шагыйрь! Димәк, аның китаплары үзем яраткан шагыйрьләр генә куела торган аерым бер киштәдә торачак! Кайта-кайта тәмләп укыр өчен… Андый шагыйрьләр, чыннан да, кат-кат укыла… Гәрчә аның иҗаты сиңа күптәннән таныш булса да, ул шигырьләрнең күбесен яттан белсәң дә…

Салават Әбүзәров минем өчен нәкъ әнә шундый шагыйрьләребезнең берсе. Дөресен әйтим, мин аның үзе белән якыннан таныш та түгел. Телефоннан сөйләшеп торабыз анысы, Уфага барып чыкканда аягөсте генә хәл-әхвәлләр дә белешкәләгәнебез бар, минем бер юбилеем уңаеннан, «Башкортостан» гәзите өчен интервью да оештырган иде. Тагын бер генә вакыйганы искә алып китим. Моннан берничә ел элек миңа Удмуртиянең халык язучысы Вячеслав Ар-Сергиның татар телендәге китабын җыеп чыгарырга туры килгән иде. Шуннан алда гына Салават Ар-Сергиның шигырьләрен, башкортчага тәрҗемә итеп, «Агыйдел» журналында бастырган иде. Шул исемә төште дә, тиз генә татарчалаштырып, ул шигырьләрне китапка кертеп җибәрдем. Салаватның рөхсәте белән, әлбәттә. Шулай итеп, Салават Әбүзәров Вячеслав Ар-Сергины татарчага тәрҗемә итүче булды да куйды. Аннары аның *«Ул чак шигырь онытылган булыр, // Җирдә беткән булыр шагыйрьләр»* дигән ике юлын үземнең бер шигыремә эпиграф итеп тә алган идем…

Күрәсез, Салаватның иҗатын күптәннән күзәтеп барам: күземә чалынганнарын, кулыма эләккәннәрен укымый калганым юк. Бәләкәй генә шәлкемнәрендә дә, кыска-кыска гына шигырьләрендә дә күңелемә хуш килерлек шигъри юллар табып куанам. Бәхетебезгә, андый шигырьләре табылып кына тора. Менә әле күптән түгел генә Уфага соңгы баруымда, «Китап» нәшрияты табасыннан төшкән өр-яңа «Гамәл дәфтәре» исемле китабын кулыма төшереп кайттым…

Салават Әбүзәровның шигырьләре нәрсәсе белән күңелне җәлеп итә соң? Ул шигырьләрнең хикмәте, тәэсир итү көче нидә? Ни өчен аның беренче шигырьләренә үк бөегебез Мостай ага Кәрим игътибар иткән? Ни өчен аның юбилей китабына кереш сүзне нәкъ менә халык шагыйре Равил Бикбаев язган? Ни өчен олуг шагыйребез Хәсән Назар аның иҗатын бик югары бәяли? Хәер, алар үз сүзләрен әйткәннәр инде, безгә сүз дә калдырмаганнар… Шулай да берничә фикеремне әйтмичә булдыра алмыйм…

Безнең өлкән дустыбыз Наҗар агай Нәҗми каләмдәшләре белән хат алышырга ярата иде. Шул исәптән мин фәкыйрегез белән дә. Аның хатлары күбрәк иҗат турында, яңа шигырьләр турында булыр иде. Ниндидер бер гади генә шигъри табышы өчен дә шатланып, тизрәк шул хакта хәбәр итә торган иде. Гомумән, әгәр дә әнә шул «ниндидер бер шигъри табышы» табылмаса, ул шигырь язарга утырмый да иде шикелле. Салаватның шагыйрьлеге дә Һади Такташ, Мостай Кәрим, Наҗар Нәҗми, Әнгам Атнабаев кебек олуг затларыбыздан, аларның шигъри мәктәбеннән килә икән. Әлбәттә, бу очракта Салават ялгызы гына түгел. Хәсән Назар шундый, Салават Рәхмәтулла, Марат Кәбиров шундый. Әле телгә килгәннәрен генә атыйм. Ирек Киньябулатов белән Мөхәммәт Закиров шундыйлардан иде…

Бер сүз белән генә әйткәндә, шигърияттәге Такташ юнәлеше бу. Үтемле тапкыр сүзләргә, көтелмәгән сүз уйнатуларга, усал кинаяләргә, афоризмнар кимәлендәге шигъри сүзтезмәләргә корылган, актуаль темаларны гына түгел, традицион темаларны да шигъри осталыкка төреп бирә торган тирән эчтәлекле шигърият. Андый шигырьләр халыкчанлыгы белән, укучы күңеленә якынлыгы белән аерылып тора. Мин үзем дә шундый шигърият яклы, шундый шигърият тарафдары! Әбит еракрак китеп карасак, ул Шәрыкнең бөек шагыйрьләреннән үк, шулай ук бөек Тукай белән бөек Бабичтан ук килә. Шөкер, аларның дәвамчылары туа тора…

Соңгы вакытта мин казакъларның бөек бер шагыйре Мукагали Макатаевны татарчага тәрҗемә итү белән мавыктым. Үзем өчен өр-яңа бер шагыйрь ачтым, үземә бик тә якын булган шагыйрьне таптым. Салаватның яңа китабын укыганда да еш кына ике шагыйрьнең рухи һәм шигъри охшашлыкларына тап булдым. Соклануымның һәм гаҗәпләнүемнең иге-чиге булмады. Чын шагыйрь нинди телдә язса да, нинди милләт вәкиле булса да, үзенчә яза, үз милләтенең чын шагыйре булып кала шул!

Мукагалинең бер шигырендә «Син миннән хәл сорама, син җыр сора» дигән юллар бар. Салаватның да бер шигыре «Хәлләремне сорамагыз…» дип башлана. Һәр шагыйрьнең үз язмышы, һәр шагыйрьнең үз хәле… Күпме охшашлыклар, күпме уртаклыклар… Әмма ике шигырь – ике төрле, бер-берсенә һич кенә дә охшамаганнар…



Хәлләремне сорамагыз,
Хәлләр мөшкел, алама.
Каян килеп юлыктым мин
Бу чукынган калага?!

Салаватның бу дүрт юлы мине аяктан екты. (Кайчан да булса шушы юлларны эпиграф итеп алып, үзем дә берәр шигырь язмый булдыра алмам шикелле. Ул, мөгаен, *«Каян килеп юлыктым мин // Бу чукынган Казанга?!» дип тәмамланыр…)* Менә кайда ул сүз тәме, сүзне урынында куллана белү осталыгы! Бөтен тарихыбыз, бөтен милли фаҗигабез, бүгенге хәлебез, чарасызлыгыбыз шушы дүрт юлга сыйган да беткән: аңлатмалар да, өстәмәләр дә, төзәтмәләр дә кирәкми, комментарийларның да кирәге юк. Барыбызның да күңелендә йөргәнне әйткән дә биргән. Шагыйрь шулай язарга тиеш! Шигырь шундый булырга тиеш! Билгеле, Салават бу шигырьне махсус рәвештә башкарак юнәлештә дәвам итә һәм күңелгә тиярлек итеп төгәлләп тә куя: *«Зинһар өчен, җылы караш // Бирегезче бер тамчы!..»* Кыска гына бер шигырьгә күпме фикер, күпме фаҗига, күпме картина-күренешләр сыйган. Бу инде шагыйрьнең үз язмышы гына түгел, тоташ милләт язмышы… Әйтер идем, милләтнең ачы язмышы…

Менә тагын кыска гына исемсез фәлсәфи бер шигырь. Ялгызлык турында, шагыйрь халәте турында. Тоташ төшенкелек, чамасыз чарасызлык… *«Барысы да сине ташлый икән, тарту көче бетсә үзеңдә…»* дигән сүзләр белән тәмамлана. Шулай, «тарту көче» дигән төшенчә зур мәгънәгә, фәлсәфи тирәнлеккә ия. Иң мөһиме, ул физика законына гына нигезләнмәгән. Биредә тарту көче лирик геройга яисә шагыйрьнең үзенә генә кагылмый, аның иҗатына да турыдан-туры карый. Ә Салават шигырьләренең тарту көче – бәхәссез. Мөгаен, мине генә үзенә тартып тормыйдыр аның иҗаты…

Күңелдә калган тагын нинди шигырьләрме? Күп алар: «Күтәрмә», «Күңел», «Базар капкасы төбендә…», «Шагыйрьләр», «Елау», «Җир өстен төн кочаклаган…», «Ходай алдында тигезбез…», «Бөекләр»… Кирәк булса, тагын да саный алам. Салаватның тагын бер кыйммәтле сыйфатын әйтеп китәсем килә. Ул да булса, гомумиләштерү сәләте. Гап-гади генә лирик шигырьне дә милли, сәяси, иҗтимагый юнәлешкә борып җибәрә алу сәләте. Шушы ук асыл сыйфат «Ир канаты», «Хәерче» поэмаларында да ачык төсмерләнә.

Ә инде китап битләре буйлап чәчелгән, күзләрне иркәләгән, күңелләрне кытыклап торган шигъри энҗе-мәрҗәннәрне санап та бетерерлек түгел:

Күңелдә гүя җыр түгел,
Зынҗыр чыңлый чың да чың…
яки
Эшең, кешем, вагырак та булыр,
Тик максатың кечкәй булмасын!..
яки
Синең белән тәмугка да
Сөрелергә әзермен.

Ә менә бу шигырьне, сүзләремнең хаклыгын раслар өчен, тулысынча китерәсем килә:

Ходай алдында тигезбез,
Беркемгә аерма юк.
Патшага да шул бер кояш,
Көтүчегә дә шул ук.
Бер үк җиһан, бер Җир шары,
Бер үк су, бер үк һава.
Бер үк кошлар моңын түгә,
Бер үк яңгырлар ява…
Бу сүзләрем ачыш түгел,
Моны һәркем дә белә.
Тик көтүче буласы килми,
Патша буласы килә…

Бу шигырьне укыганнан соң: «Шулай шул!» – дип авыр суларга гына кала…

«Атайсызлык» поэмасын укып чыкканнан соң, мин Салаватның күңел халәтен, эчке кичерешләрен, балачак хатирәләрен тагын да ныграк аңлый башладым шикелле. Шушындый ук поэманы мин дә язарга тиеш идем, тик ни сәбәптәндер яза алмаганмын. Ә менә Салават язган! Минем өчен дә! Әтисез үскән башка малайлар өчен дә… Әтисез үсү ничек авыр булган булса, әтисезлек турындагы поэманы язу да шулай ук авыр да, газаплы да булгандыр. Ятим балачакка яңадан әйләнеп кайтуның, кичерешләрнең, күңел яраларының яңадан кузгалуын тоюның газапларын әтисез үскән малайлар үзләре генә белә… Андагы бөтен вакыйгалар да, бөтен хисләр дә миңа үтә дә якын, үтә дә кадерле, шул ук вакытта үтә дә газаплы… Салаватның балачагын, аның туганнарын, әнисен күз алдыма китердем; үзебезнең малай чагыбызны, әле берничә генә ел бакыйлыкка күчкән Әнкәебезне хәтерләдем. Салаватлар да бишәү булган икән, без дә…

Әтисезлек, балачагында кичергән гаделсезлекләр, кимсетелүләр сине гомер буе эзәрлекли. Тормышта да үзен һәрчак сиздереп тора, сиздермәстән генә иҗатыңа да килеп керә. Шушы халәт Салаватның иҗатында да аермачык булып ярылып ята: милләт язмышы өчен борчылу, социаль гаделсезлекләргә ризасызлык белдерү, җәмгыятьтәге тискәре күренешләргә, кимчелекләрне тәнкыйть итү… Ләкин үзенчә, үзенә генә хас шигъри алымнары белән, үзенең осталыгы белән… Ул туган телен, шигырь теленең кадерен белеп, тәмен тоеп, әйтәсе сүзенең, уй-хисләренең, фикерләренең бәясен аңлап, үзенең остазларының йөзенә кызыллык китермәслек итеп яза. Күренекле башкорт шагыйре Салават Әбүзәровның «Гамәл дәфтәре»н укып чыкканнан соң шундый катгый нәтиҗәгә киленде. Әгәр дә калган укучылар да язганнарым белән килешсә, фикерләремне, уйлануларымны хупласа, мин, билгеле инде, бик тә мәмнүн булыр идем.

«Хыял күккә әйдәгән чак»

ШИГЪРИЯТ

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ

УРЫННАРЫ БИЛГЕЛЕ

Чыңгыз ханның төрбәсе юк,
Эзләнәләр, әмма тапмыйлар.
Бардыр ул, бар! Чит-ятларга
Күрсәтмиләр, серне саклыйлар.
Күчем хан да шундый хәлдә.
Беркем белми: кайда күмелгән?
Аның карау алар икесе дә
Балкып тора хәтер түрендә.
Кирәк түгел кабер эзләү,
Ләхетләре безнең күңелдә!
Милләтенең данын күтәргәннәр
Халкы йөрәгенә күмелә...

СЫЕК БУЫНЛЫ БУЛГАЧ

Чеченнарның ана телле
Мәктәбен ябып кара.
Ник тудымга төшерерләр
Батырып кара канга.
Бездә андый куркыныч юк,
Бетерәбез бик теләп.
Өстән төшкән һәр әмергә
Башны иеп, бит терәп...

БУМЕРАНГ БУЛМАСМЫ?

Их, бабайлар!
Равил Фәйзуллин

Бабайларны гаепләргә
Хакыбыз юктыр югын.
Ачу да килеп куя шул
Карасаң тарих юлын.
Көчләр тигез булмаган дип,
Аңлатма табып була.
Дәүләтсезлек ничә гасыр
Сулышны кыса, буа.
Көрәш әле дәвам итә.
Без исән! Шуңа шөкер.
Күсәк тоту чоры түгел,
Төп корал бүген – фикер!
Һәр мөмкинлек кулланылсын,
Эзләник, уяу торыйк!
Үзебезгә: –Их, бабай! – дип
Әйтмәслек булсын оnык...

БАРЫБЕР РӘХМӘТЛЕМЕН

Кош иканне белӛм лә мин,
Очып кына китәлмим.
Күкләр язган кагыйдәгә
Үзгәрешләр кертәлмим.
Канатым бар. Кала инде
Хыялда кагынырга:
Шундый мөмкинлек калдырган
Ходама табынырга...

ЯШЬЛӘР АҢЛАП БЕТЕРМИ

Җитәкчебез онытканмы
Үткән авыр чорларны:
– Алтмыш биш яшь бәйрәм түгел,–
Диеп борып чыгарды.
Үзе җитсә (...) аңлар әле,
Чын әйтәмме, юриме:
Алтмыштан соң килгән еллар
Һәммәсе дә – юбилей!

КАЙЧАН ҖИТЛЕГЕРБЕЗ?

Бер карасаң, безнең тормыш
Нәкъ балалар бакчасы.
Әнигә җыр багышлыйлар
Яше, карты – барчасы.
Сурәтләнә куллар, күзләр...
Бар елата торганы.
Тасвирланмый калды бугай
Бары аяк тырнагы.
Күпсенүдән түгел сүзем,
Түгел үпкә яңарту.
Бик табигый, күркәм гамәл
Изге затны ярату.
Кайчан балигъ булырбыз соң?
Эшләр күп бит, нишләргә?!

Вакыттыр дим әниләрнең
Итәгеннән төшәргә...

БИК ТИЗ ЧИСТАРЫРБЫЗ

Командирлар солдатларны
Ялгышудан кисәтә:
– Делай как я! – диеп, әүвәл
Үзе эшләп күрсәтә.
Шәхси үрнәк мисалында
Аңлашыла күп нәрсә.
Өйрәнербез... өстәгеләр
Гадел яшәп күрсәтсә!

ИКЕЙӨЗЛЕЛЕК

– Авылларны ничек сакларга? – дип,
Гүләп тора киңәш-үгетләр.
Авторлары туксан сәбәп табып
Авылыннан (...) киткән егетләр...

КӨЧЕГЕЗ ҖИТСӘ

Иген игеп, мал-туарлар карап
Сала тормышына күнеккәнмен.
Бодай сагызыннан җилем ясап
Туып-үскән җиргә береккәнмен.
Беләм, дуслар, мине янгызда,
Биеклектә көтә күпләрегез.
Шартым бар шул: өскә – югарыга
Аулым белән бергә күтәрегез!

ТЕЛӘСӘҢ, ҖАЙ ТАБЫЛА

Ыктан төшәм Агыйделгә,
Керәм Чулман, Иделгә.
Тарихтагы Илем аша
Барып җитәм диңгезгә.
Чыгар юлны халык таба,
Томала-томалама.
...Безне читлеккә яптым дип
Ялгышкан бер (...) томана...

БАТЫРЛЫК МӘСЬӘЛӘСЕ

Батырлык ул – зур максат хакына
эшләнгән ахмаклык.
Марат Кәбиров

Кызык карап ямь тапкандай,
Күпме халык тик тора.
Берәү суга ташлана да
Батучыны коткара.
Дөрләп янган утка кереп
Исән алып калалар.
Курку хисен җиңә торган
Көчне каян алалар?
Тормышта гел очрап тора
Тәвәккәллек – матурлык.
Һәркем булдыралмаганны
Эшли алу – Батырлык!

ГАЕПЛӘРГӘ АШЫКМАГЫЗ

Матур сурәт гел үзенә тарта,
Туктап калып булмый күз күргәч.
Нишләргә соң безгә, янәшәдә
Чибәр кызлар шулай күп булгач?!

ЕКСАҢ ЕК ИНДЕ

Бетерергә уйладың син мине
Яраттырып.
Күптән онытылган хисләремне
Яңарттырып.
Шунсы гаҗәп: гел генә дә килми
Карышасым.
Кыз ярәшеп йөргән егетләрдән
Калышасым.
Матур-матур сүзләр җыеп йөрим,
Тәҗелләрен.
Борчылма син. О'кэй булыр. Мин бит
Тәҗрибәле!

ГАРЬЛӘНҮ ЯРДӘМЕ

Учагыңда яндырдың да
Көлемне ташлап киттең.
Үпкәләмим. Түбәнсетеп
Син мине шагыйрь иттең.

КҮҢЕЛ КЫЛЫБЫЗ – ИСӘН!

Өзелсә дә башкалары –
Туктамаган, куймаган:
Паганини сыңар кыллы*
Скрипкәдә уйнаган.
Гаҗәпләнмим.
Безнең мәнә
Соңгы кыл да өзелгән.
Ялгый-ялгый уйнаганга,
Моң көчлерәк... түзелә...

**Италиянең виртуоз скрипкачысы.*

ЧИЛЕ-ПЕШЛЕ ТИЗ ҮРЧИ

Чыгымнардан куркып тормый,
Ашамаса ашамый;
Ябырылып концерт карый,
Милләттәшен ташламый.
Такмакчылар саны тиздән
Өч меңгә, ди, җитәсе.
Ничә «җырчы» күтәрәлер
Татар халкы җилкәсе?!

АЛАР ӨЧЕН «БОРЧЫЛАМ»

Алда еллар бик өметле:
Юлда хәвеф бетәчәк.
Машиналарны бик тиздән
Робот «шофёр» йөртәчәк.
Кагыйдәне төгәл үтәп
Ипле, салмак чабарлар.
...Гаишниклар ришвәт-керем
Инде кайдан табарлар?

АҢЛАТЫП КАРА ИНДЕ

Мы есть то, что едим.
Табиблар вәгазе.

Туры килеп бетми торган
Әйтемнең күптер саны.
Кытайлар ак дәгә ашый,
Үзләре нигә сары?

СЫНАЛГАН ЫСУЛ

Чибәр ханым доктор була ала,
Уңай тавыш җыя шунда ук:
Академикларга күренәлсә,
Кандидатом сердечных наук...

ЮГАРЫ СӘНГАТЬ ЮЛЫНДА

Розалина Шаһиева кая гына килеп кермәсен, күргәзмәләр залымы яки музеймы, форум-симпозиум булсынмы – ул килеп керүгә, тамаша барган мохит ничектер тулыланып киткәндәй була. Үзенең чыгышларын ул тонык, акрын тавыш белән ерактан – әллә нинди көтелмәгән ассоциацияләргә этәрә торган кереш сүз белән башлап җибәрә, очкыч җирдән аерылыр алдыннан тизлек туплаган кебек, фикерен төйни һәм тора-бара катгый яңгырашлы тавыш белән, сүз барган күренеш-фикер хакында төп-төгәл билгеләмәсен әйтеп бирә…

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТ

Мәдхия генә җырлап калмыйча, һәрвакыт, иҗат кешесенә үз сукмагы белән барганда нәрсәгә игътибарлы булырга кирәклеген искәртә. Тәнкыйтьли калса да, дуамалланып, алны-артны күрмичә, шәхесне бетереп ташламый. «Менә мондый ысул да бар бит әле, алда әле сезне үзегез дә көтмәгән шундый ачыш-могҗизалар көтә», – дип, рәссамны яңа үрләр яуларга өнди. Әйе, ул дипломат та, сәясәтче дә. Узган гасырның 90нчы елларында дәүләтчелек өчен көрәш барган дәвердә ул чыныккан, үз чорыннан дәрт һәм колачлык алган «хөррият кошы» да иде. Аның икенче тәхәллүсе – «Ниса». Юнан Никасы кебек канатларын кагып, бөтендөнья иҗат әһелләренә: «Әйдәгез, алга! Илһам артыннан ияреп, җәмгыятькә, кешелеккә, йөрәге сәнгать дип типкән адәми затларга хезмәт итик!» – дип чакырган Ниса ул. Барыннан да бигрәк, аның үзенә дә илаһи канатлары, илһамы, сәнгать дәрте кадерле, чөнки үзе дә күләмле сәнгать, яңа типтагы мәдәни пантеоннар тудыручы. Розалина Шаһиеваның эшчәнлеге музейлар белән дә тыгыз бәйләнгән. Тарихта беренче бөтендөнья татар Милли мәдәнияте музее, «Хәзинә» галереясына фундамент биргән Татарстанның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда 1970-71 елларда археолог Альфред Халиков, сәнгать фәннәре докторы Фоат Вәлиев белән оештырган татар сәнгате бүлеге; «Казан» милли мәдәният үзәге карамагындагы биш филиал: Бакый Урманче, Илдар Зарипов, Әмир Мәҗитов, Константин Васильев, сугыш каһарманнары музейлары – барысына да аның хезмәте кергән. Ул аларның фәнни нигезен төзегән, үз куллары белән беренче карамаларын-эскизларын башкарган…

Икенче зур эше – татар сәнгатен дөньякүләм дәрәҗәдә таныту: моның дәлиле – чит илләрдә – Будапештта, Абу-Даби, Мәскәү һәм Истанбул, Париж һәм Хельсинки, Италиянең Пиза шәһәрләрендә булып үткән күргәзмәләр, Рәсәй форматындагы альбом-каталоглардагы мәкаләләр. Аңа Венгрия, Иран, Багдадтан, Америкадан, Бельгиядән килгән рәхмәт хатлары… Аның иҗади импульсын күргәзмә-музейлар гына түгел, Илдар Зарипов, Абрек Абзгильдин, Әхсән Фәтхетдинов, Зиннур Миннәхмәтов, Фиринат Халиков, Шамил Шәйдуллин, Рабис Сәлахов кебек татар сәнгатенең йөзен билгеләүче күренекле кылкаләм осталары да таныды һәм аларның иҗади язмышында Розалинаның роле бәхәссез.

– Әгәр дә син иҗат әһеленең күңел кичерешләрен, йөрәк тибешен тоймыйсың икән, ничек итеп чын-чынлап аның турында фикер йөртмәк кирәк, – ди ул.

Аның фаразлаулары рас килә бара. Әйтик, рус реалист рәссамы Владимир Попов – Иранда җиңү яулап кайткан каллиграф, дөньякүләм мәшһүр рәссам, «Алтын каләм»ле Поповка; ә мәҗүси иконалар язучы Чаллы рәссамы Анатолий Пашин бөек татар бестселлеры «Йосыф белән Зөләйха»га иң яхшы иллюстрацияләр тудыручы Талибҗан Пошымга әйләнделәр. Алар үз тормышларындагы бу әверелүләр өчен Розалинага мәңгегә рәхмәтле.

Бу шигъри дәрт белән аналитик фикерләү байлыгы каян килә соң?

Розалина тумышы белән авылдан. Авыл мохите – аның балачак бишеге. Бикет, Бишнә, Карауҗа – Яшел Үзән районының авыллары аның туган җире. Ул вакыттагы авыл тулы һөнәр ияләре: берсе – умартачы, икенчесе – чабата үрүче, өченчесе – кирпеч сугучы, дүртенчесе – чигүче, күнче, тегүче, бишенчесе – кич утырып Йосыф-Зөләйханы көйләүче. Балачактан ук шушы һөнәрчеләрнең эшләрен күреп, әкият-риваятьләр тулы халык иҗаты дөньясында тәрбияләнгән шәхес Розалина Шаһиева. Аның ары бабалары – дәү әни, дәү әтиләре – шагыйрь, музыкант, җырчылар. Әтисе – музыкант, шагыйрь, рәссам. Репин, Шишкин әсәрләрен күчереп ясаган, гобойда уйнаган. Абыйсы – полиграфист, хәреф җыючы. Әтисенең абыйсы исә Ленинград камалышын үз башыннан кичергән каһарман – ике аягын яу кырында өздереп тә исән калган офицер. Менә шушы мохит тәрбиясендә үсә Розалина.

«Мәңгелек гөлләре» дип аталган күләмле хезмәтендә дә аның балачакта алган тәэсирләре, халык сәнгатенең тылсымлы тарту көче чагылыш тапкан. Бала чакта алган хатирәләр барысы да профессиональ сәнгать белгеченә әверелеп яңа бер баскычка күтәрелгәч, саллы-саллы мәкаләләрдә чагылыш тапкан. Китапның беренче бүлеге тулаем халыкның самими иҗатына багышланган. Һәр өлкәнең – каюлы күнме, чигүме, зәркәнчелекме, зәвыклы милли киемме – һәрберсенең тирәнгә үтеп кергән борынгы тамырлары табылган. Алар тора-бара профессиональ төс алып, бүгенге татар сәнгатенең самими, үзгә, кабатланмас панорамасын булдыралар да инде. Безнең беркемгә дә охшамаган үз йөзебезне, татар сәнгатенең портретын тудыручы фактор ул, һичшиксез, кул һөнәре сәнгате. Милли мәдәният музеена килгән һәр кеше экспозициянең күрке булган «Казан тажы» янында туктала. Аның төп нөсхәсе Мәскәү Кремленең Корал пулатында сакланан дөньякүләм шедеврлар исемлегенә (реестрына) кертелгән. Розалина Шаһиева татарлардан беренче буларак аны (Казан ханнарын, рус хөкемдарын исәпкә алмаганда) киеп карый һәм аның нәкъ менә татар халкының кул һөнәре иҗаты, үз мирасы икәнлеген дәлилләгән һәм шуның буенча бүгенге татар ювелирлары «Казан тажы»ның күчерелмәсен эшләгән.

Әлеге музей аша ул галимнәр белән үз халкының мәңгелек тарихын, бөек сәнгатенең барлыгын исбат итте. ЮНЕСКОның музейлар бүлеге мөдире Ив Джонс: «Бу музей (Милли мәдәният музее – татар халкының тарихы, мәдәнияте, бүгенгесе киләчәге турында авыз тутырып сөйли торган беренче музей) – шәрык Аурупасының иң яхшы музейлары рәтендә. Димәк, татарның үз йөзе бар дигән сүз һәм ул Гиннесс китабында теркәлерлек», – дигән фикердә кала.

Аның сәнгать җәүһәрләре, төрки балбаллардан алып – зәркәнчелек, каюлы күн, XX гасыр татар авангарды, югарыда әйтеп узган «Казан тажы», Явыз Иванныкы дип исәпләнгән патша тәхете дә – безнең татарныкы икәнен исбатлаган. Боларның искиткеч төгәл күчерелмәләре (бу исә музейлар практикасында еш кулланыла) – Милли музей экспозициясенең йөзек кашы.

Мәдәният әһелләренә килгәндә исә сәнгать белеме патриархлары – Бакый Урманче, Фоат Вәлиев. Бу ике титан – икесе дә Розалинага кыйбланы күрсәтүче. Урманченың иманлы, күләмле, гасырларны тоташтыручы милли сәнгать, дип талпынуы, Вәлиевнең татар сәнгатенең киләчәген күзаллавы, аның тарафдары Розалинага васыяте… Болар барысы да аның тирән, хисле, ләкин хакыйкый мәкаләләрендә «Мәңгелек гөлләре» китабында тасвирлана.

Ул Һиндстаннан алып Мексикага кадәр дөньяны иңләгән һәм шуңа күрә күзаллавы гаять дәрәҗәдә киң. Аның өчен иң мөһиме – күпне белү һәм үз чорыннан артта калмау. Шигърият булсын, сәнгать, әдәбиятмы, музейлармы – һәммәсе мәңгелек кыйммәтләр. Ләкин аның фикеренчә, музейлар гел үзгәреп, яңарып, бүгенге көн югарылыгында яшәргә тиеш.

Розалина – дөньяны, сәнгатьләрне, телләрне, мәдәниятләрне бергә бәйләүче алтын җепкыр ул. Урта Азия, Алтай, Кавказ, Балтыйк буе, Мексика, Америка… Аны бигрәк тә соңгы елларда Америка индеецлары һәм татарның кием-салым, зәвык, музыкадагы уртаклыклары кызыксындыра. Шуңа күрә Нью-Йоркка баруга андагы индеецлар музееннан кайтып керми.Тел, музыка, кыяфәт, кием уртаклыклары. Каюлы күнне генә алыйк, монда да зур тиңдәшлек. Бездә ефәк җепләр белән чигү, аларда – сәйлән. Уртак чыганак – чәмчәле чигү. Борынгы Кытайда церемония театры булган – аны «Цам» театры дип атаганнар (Кытайның «цам» татарның «чәм»енә әйләнгән). Анда шушы, бездәге лалә чәчәге белән бизәлгән, аждаһа – канатлы елан сурәтле «чәмчәле» читек киеп, театр уйнаганнар. Шул техниканың сәйләнле төре индеецларда да сакланган…

Розалина – тиктормас җан. Мәсәлән, хәзер ул ике проект, ике китап өстендә эшли. Эшли дип, аларны аз гына тәртипкә китерәсе дә нәшриятка илтеп тапшырасы гына кала. Болар – «Татар киеменең (костюмының) мифологиясе» һәм икенчесе – «Сынлы сәнгатьтә Сөембикә образы». Сөембикә дигәннән, аның үзе турында да язарга туры килә. Рәссам Фиринат Халиков Казанның меңьеллыгы алдыннан «Нурлы Казан» дигән купфигуралы әсәрен иҗат иткәндә, Розалина ханым аңа гел ярдәм итеп, галимнәр белән фикер алышып, яңадан-яңа мәгълүмат өстәп тора. «Ташаяк» базарына (ул хәзерге үзәк стадион, «Пирамида» тирәсендә булган) салым түләргә халык җыела торган булган. Базар гөж килгән. Барысы да уң якта утырган Сөембикә-ханбикәгә юнәлгәннәр… Сөембикәне ясыйсы бар… Кемне модель итеп алырга? Берзаман рәссам сискәнеп китә: «Әнә бит Шаһиеваның йөз чалымнары, табигате, фигыле, акылы – барысы да хөкемдар, сәясәтче, шагыйрә, тәвәккәл дәүләткяр һәм бәетләр чыгаручы Сөембикәнеке белән тәңгәл килә түгелме соң?»

Ул аңа сабыр гына карап ала да (Розалина үзе сизми дә) йөз чалымнарын эскизга төшерә. Хәзер бу монументаль әсәр музей экспозициясенең икенче залында.

Әйе, дөньялар үзгәрә, вакыт уза, патшалар алышына, ләкин шунысы ачык – тарих кала, иҗат кала, фикер кала! Тикмәгә генә китапның исеме «Мәңгелек гөлләре» түгел. Мондагы шәхесләр, чынлап та, татар тарихы, мәдәниятенә кереп калган зур бер гөл бәйләме кебек – һәрберсенең үз тәэссораты, юнәлеше, узганы һәм киләчәге бар. Хәрәкәттә генә түгел, сәнгатьтә дә бәрәкәт бар. «Кәчәбә» Розалинаның хәрәкәте туган илгә бәрәкәт китерсен.

Рәсим МӘҺДИЕВ,
Татарстан Халыклар дуслыгы йортының күргәзмәләр бүлеге мөдире.

Нияз Бишбалта төзеде.

Чайнворд

«Татар табышмакларын беләсезме?»

1. Ике аяклы үгез, маңгаенда куш мөгез.
2. Ияре дә, дугасы да үзендә.
3. Төнлә йөрергә ярата, көндез йөрми, йокыга ята.
4. Күзе дә юк, колагы да юк; үзе сукырны җитәкли.
5. Елмый агай елмаеп боз эретә.
6. Иелә, бөгелә, ак мамыгы түгелә, кара күзе күренә.
7. Канаты бар, аягы бар – йөзә алмый.
8. Ач булса – ята, тук булса – торып утыра.
9. Үзе сукыр, кешегә юл күрсәтергә оста.
10. Ишекле-түрле йөри, эләккәнне сөйри.
11. Башы тауда, аягы диңгездә.
12. Син аны тота барасың, ул синнән кача бара.
13. Армый-талмый, ат артыннан калмый.
14. Өй өстендә ярты күмәч.
15. Аяксыз-кулсыз өй саклый.
16. Аягында кара ката, тәпиендә кызыл оек, яшел күлмәкле, ак яулыклы.
17. Җәрәхәте юк – авырта, төтене юк – яна.
18. Үзе укый белмәсә дә, гомер буе язына.
19. Гәүдәсе өйдә, башы тышта.
20. Яз килсә – киенә, көз килсә – чишенә.
21. Тау куенында анасы, чыгып кача баласы.
22. Башы тарак, койрыгы урак.

Җаваплар.
1.Велосипед **2.**Дөя **3.**Ярканат **4.**Таяк **5.**Кояш **6.**Шомырт **7.**Тавык **8.**Капчык **9.**Компас **10.**Себерке **11.**Елга **12.**Акча **13.**Арба **14.**Ай **15.**Йозак **16.**Карабодай **17.**Йөрәк **18.**Калам **19.**Матча **20.**Агач **21.**Чишмә **22.**Әтәч.

«ЗАО «Камдорстрой Автобаза-48» требуются водители кат. C, D, E, машинисты автокрана. Вахтовый метод, з/п сдельная.
Тел.: 8-937-581-22-01, 8-906-117-15-12 (водители), 8-919-632-58-60 (автокрановщики), (8552) 46-67-18.
РЕКЛАМА

РЕКЛАМА
Май аенда карпатка, карника токымлы аталанган ана кортлар сатабыз.
Т. 8 965 583 71 45 Радик 8 937 298 77 64 Фаим

Аттестат выданный 18.06.2001г. под номером **А №6847375** на имя Чирушкиной Алии Владимировны, в МБОУ среднюю общеобразовательную школу №82 с углубленным изучением предметов, прошу считать недействительным в связи с утерей.

Бөтен кызыклы мәгълүмат бер урында
www.shahrikazan.com

Россиядә наркотикларның таралышы белән бәйле вазгыять элеккечә киеренке булып кала бирә. Бу хакта РФ Куркынычсызлык хезмәте секретаре Николай Патрушев хәбәр итте. Аның сүзләренә караганда, соңгы елларда теркәлгән саннар буенча, «балигъ булмаганнар арасында наркотиклар куллануның шактый күпкә, төгәлрәк итеп әйтсәк, 60 %ка (!) кадәр артуы» борчылырга мәҗбүр итә. Татарстанда, шөкер, хәлләр ул кадәр үк начар түгел икән. Әмма бу – тынычланып калырга да ярый дигән сүз түгел, ди ТР Республика наркология диспансерының балалар наркологиясе буенча баш табиб урынбасары Степан Криницкий.

Степан Криницкий:
«Җиңел» наркотиклар дигән төшенчә юк, алар барысы да – авыр»

– Степан Матвеевич, бүген Татарстанда балалар наркоманиясе үсешенә бөтенләй нокта куелды, йә булмаса, ул сизелерлек дәрәҗәдә кимеде, дип әйтеп буламы?

– Һичшиксез. 90нчы еллар азагында – нуленче еллар башында – республикада героин һәм аңа бәйлелектән интегүче балигъ булмаган яшьләр күп иде. Тора-бара героин сирәк очрый торган наркотиклар рәтенә күчте – полиция тарату каналларының күпчелегенең эшен туктата алды. Хәер, аның артыннан ук башка бәла пәйда булды – психоактив матдәләрнең яңа төрләре. Болар: спайслар, тозлар, һәртөрле микслар... Бүген без хәлнең бераз уңайлануын күзәтәбез. Моны профилактика һәм диспансерда теркәлү узар өчен китертелгән укучылар белән студентлар арасында тикшерү уздырганда ачыклыйбыз.

– Саннарга килсәк, ничегрәк?

– Без «балалар наркоманиясе» төшенчәсенә караган дүрт юнәлеш буенча да саннарның кимүен күзәтәбез. Менә ул юнәлешләр: токсикомания, наркомания, наркотиклар һәм агулы матдәләрне даими куллану. Токсикомания буенча, мәсәлән, саннар бөтенләй кимеде – республика күләмендә учетта нибары 4 кеше генә тора. Наркоманиягә килгәндә, хәлләр болайрак: 2015 елда 115 кеше барлыгын ачыкласак, 2016 елда бары 57 кеше генә теркәлде. Даими кулланучылар буларак 82 кеше теркәлгән, наркобәйлелектә 18 кеше (бер бала һәм унҗиде яшүсмер) санала.

– Иң авырткан урыныбыз кайда?

– Без наркотикларны «җиңел» төрләргә бүлү яклы түгел, алар барысы да – «авыр». Алар барысы да кешедә бәйлелек уятып, аның дөньяны кабул итүен бозалар һәм тормышын җимерәләр. Аңлашыла инде, тормышында алга таба килеп чыгачак борчуларга да нигез булып торалар.

– Балаңның наркоман икәнлеген ничек күреп алырга мөмкин? Бәйлелекнең тамыры тирән җәелгәнче, нәрсә эшләргә?

– Иң мөһиме: үзегезне невроз хәленә җиткерерлек итеп талкымагыз – балаларга мондый мохиттә яшәү бер дә рәхәт түгел. Рецепт бирәү генә – бала белән даими элемтәдә, бәйләнештә булу кирәк. Бигрәк тә ул күчеш чорын кичергәндә, чөнки нәкъ менә шушы чорда яшүсмер абруй булырдай затларны яшьтәшләре арасыннан эзли башлый. Кемгә карап үрнәк алырга тиеш ул? Тормышын җилгә очыру белән мавыгучы «алтын яшьләр»гәме? Бу очракта бала, иртәме-соңмы, барыбер наркотикларга киләчәк. Хәвеф барлыгы турында хәбәр итүче беренче билгеләр: шикле яңа танышларның пәйда булуы, даими рәвештә акча кирәк була башлау. Бүген баланы күзәтү, контрольдә тоту кыен түгел – шалтырату да җитә. Әгәр балагыз сезнең контрольне авыр кабул итә, каршылык күрсәтә, читләшә башлый икән, монда инде борчылырга урын бар.

– Баласы наркотиклар куллана дигән шиге туган ата-ана үзен ничек тотарга тиеш?

– Иң мөһиме – паникага юл куймагыз. Әгәр бала ачыктан-ачык сөйләшүгә әзер түгел икән, ул ышана, хөрмәт итә торган башка туганнарыгызны ярдәмгә чакырыгыз. Ә инде арагыздагы элемтәне бөтенләй җайга сала алмасагыз, психолог кирәк булачак. Шикләрегез тирәнәя төшкән очракта, ата-ана хокукларыннан файдаланып, баланы безгә тикшерүгә алып килергә мөмкин. Зарарлы матдәләр калдыклары буенча да нәтиҗә чыгарырга мөмкин булачак.

Әңгәмәдәш – Катерина КОТОВА

АФИША
24-30 АПРЕЛЬ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

24 апрель «Гүзәлем Әсәл» (Ч.Айтматов)
Г.Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

25 апрель «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум

26 апрель «Мулла» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

27 апрель «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 11.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

27 апрель «Көтәм сине...» (И.Зәйниев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум

28 апрель «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 10.00
Билет бәясе: 200-250 сум

28 апрель «Дон Жуан» (Ж.Б.Мольер)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум

29 апрель «Дәрсе гыйбрәттер театр...» (Р.Мөхәммәтшин)
Башлана: 12.00, 12.25
Билет бәясе: 300 сум

29 апрель «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт, С.Ваннус)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум

30 апрель «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

25 апрель «Беренче мәхәббәт» (И.Гали)
Башлана: 18.30

26 апрель «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.30

27 апрель «Бер күрешү – үзе бер гомер!» (Ф.Яруллин)
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 300-1000 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

26 апрель «И кызык Шүрәле!..» (Г.Зәйнашева)
Башлана: 13.00, 23.00

27 апрель «Апушның тылсымлы төшләре» (Р.Бухараев)
Башлана: 11.00, 13.00

28 апрель «Апушның тылсымлы төшләре» (Р.Бухараев)
Башлана: 11.00, 13.00

29 апрель «Кәҗә белән Сарык» (Г.Тукай, Г.Рәхим инсц.)
Башлана: 11.00, 13.00

29 апрель «Су анасы» (Г.Тукай, З.Хәснияр инсц.)
Башлана: 15.00

29 апрель «Ханума» (олылар өчен спектакль)
Башлана: 18.00

30 апрель «Не хочу, не буду!»
Башлана: 10.00

30 апрель «Су анасы» (Г.Тукай, З.Хәснияр инсц.)
Башлана: 11.00, 13.00
Билет бәясе: 250-600 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ,73)

24 апрель Эльмира Галимова юбилей концерты
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 500-800 сум

24 апрель «Россия казаклары» бию театры
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 500-1600 сум

«ПИРАМИДА» МӘДӘНИ-КҮҢЕЛ АЧУ ҮЗӘГЕ
(МӘСКӘҮ УРАМЫ, 3)

27 апрель Elvin Grey концерты
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 950-2000 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Язучы Марсель Галиевнең «ТЫНЛЫК ДӘШКӘНДӘ» дип аталган фотокүргәзмәсе
Керү ирекле (эш көннәрендә).

5+

100 МЕҢ СУМ отасың киләме? Йөгер!

Идар Мөхәммәтҗанов фотосы

СПОРТ

Казан марафонына бер айдан азрак вакыт калып бара. 21 май көнне булачак ярышка спортчылар көчләре җитәрлек дистанция сайласа, оештыручылар акча саный. Татарстанның яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов белдерүенчә, быел Казан марафонын уздыру 25 миллион сумга төшәчәк.

Адел ВАФИН, Татарстанның сәламәтлек саклау министры:

Скандинав йөреше таяклары култык таякларыннан яхшырак. Терәк-хәрәкәт аппараты авыруларына каршы көрәш еленың символы нәкъ менә скандинав таяклары булырга тиеш. Бер караганда бик җиңел булып тоелган әлеге спорт төре мускулларның 90 процентын хәрәкәткә китерә. Җәрәхәттән саклану өчен менә дигән әйбер ул.

– Казан марафоны республикадагы чабышларның бер өлеше генә әле, ләкин иң масштаблы өлеше. 25 миллион ул формаль сан гына. Иганәчеләрнең бер өлеше су, җиләк-җимеш кебек әйберләр белән ярдәм итә. Марафонга киткән чыгымның 70 проценттын катнашучыларның кертеме каплый, – ди Владимир Леонов.

TatarRun йөгерү серияләре директоры Вадим Янгиров сүзләренчә, иң кыйммәтле ара – марафон дистанциясе (озынлыгы 42,2 чакрым). Спортчыларга аның өчен 2000 сум түләргә туры килә. Чакрымнар кыскарган саен, кертем күләме дә кими.

– Марафонның приз фонды быел ике тапкыр зуррак. 42,2 чакрым арада беренче килгән кешегә 100 мең сум каралган. Гадәттәгечә, хатын-кызлар ирләрдән 15 минутка алданрак башлаячак, – диде Вадим Янгиров.

Узган ел Казан марафоны СПИДка каршы актив көрәш шигарендә оешты-рылуы белән истә калган иде. ВИЧ авырулы кешеләр башка спортчылар, хакимият җитәкчеләре, шоу-бизнес йолдызлары белән бергә йөгерде.

ВОЛЕЙБОЛ. 28-29 апрельдә Казан белән Мәскәүнең «Динамо» командалары Россия чемпионы исеме өчен көрәшәчәк. Финал сериясе матчы 19.00 сәгатьтә Казан волейбол үзәгендә булачак.

ВЕЛОСПОРТ. 23 апрель көнне Казанда рәсми рәвештә велосипед сезоны ачыла. Велосипедчылар әлеге вакыйганы Таулар – Әмәт урман-паркында бәйрәм итә. Бирелә велосипедта 100 метрга узыш, балалар узышы, матурлык бәйгесе кебек төрле кызыклы чаралар оештырыла.

СТУДЕНТЛАР ЯРЫШЫ. 22-27 апрель көннәрендә Россия вузлары арасында «Физик культура һәм спорт – табибның икенче һөнәре» дигән студентлар фестивале уза. Анда медицина һәм фармацевтика юнәлешендә белем алучы 790га якын студент катнашачак. Араларында Кытай студентлары да бар. Булачак табиблар ГТО нормативларын тапшырачак, шулай ук волейбол, баскетбол, өстәл теннисы, йөзү, шахмат, дартс, гер күтәрү һәм бадминтон буенча ярышларда катнашачак.

ФУТБОЛ. 23 апрель көнне Россия чемпионаты кысаларында, «Рубин» Самараның «Крылья Советов» командасы белән очраша. Матч 14.30да Самараның «Металлург» стадионында уза.

26 апрельдә исә Казан футболчылары барлык җанатарларны Грозный шәһәренең «Терек» командасы белән узачак матчка чакыра. Керү – бушлай, «Рубин» «Казан-Арена» стадионындагы барлык билетларны үзе сатып ала. Спортчылар моны команданың туган көненәдәге уңышсыз уеннары өчен гафу үтенү дип аңлатты.

Алисә САБИРОВА.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1642. Гомуми тираж – 6179.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 704. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы